# ШУРА

№ 41
2023



*Мөхәррам ае*
мөбарәк булсын!

2000999960673

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ
1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Мөхәррам ае фазыйләте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14

Адәм балаларына ихтыяр көче бирелгән . . . . . . . . . 18

Гашурә көне фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . 25

Сыер кыйссасының хикмәте . . . . . . . . . . . . . . . . 29

Ибраһим галәйһиссәлам – тәвәккәл итү үрнәге . . . . . . 38

Аллаһының рәхмәтенә өметләник. . . . . . . . . . . . . 45

Хәләл хезмәт хакының кыйммәте . . . . . . . . . . . . . 50

Гыйлем алу фазыйләте. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

Гошер садакасы бирү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

Ислам дине тынычлыкка өнди . . . . . . . . . . . . . . . 66

Пәйгамбәребезнең мәүлиде. . . . . . . . . . . . . . . . 70

Олыларны хөрмәт итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78

Нәрсә ул фитрый иман? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

Март – Июнь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

Татар мәкаме белән азан әйтү турында . . . . . . . . . 120

Иман һәм сугыш (Җиңүнең 78 еллыгына багышлана) . . . . . . 124

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Казан,
Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ильяс Гарифуллин

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов
shutterstock.com сайтындагы түбәндәге авторларның материаллары кулланылды: Babamikail, Artistic Design-001, Archon7th

**«ШУРА» дини альманах, № 41**

июль – сентябрь 2023
зөлхиҗҗә 1444 – рабигыль-әүвәл 1445

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 27.06.2023
Чыгу көне: 12.07.2023

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ❁ دَاعِينَا إِلَى اللهِ❁ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ❁ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!❁ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ❁ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

________________________________ ❁

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________ ❁

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللّٰهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللّٰهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللّٰهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوٰةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللّٰهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةِ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләẓии һәдәәнә лиһәәẓәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләәән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләẓии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйẓү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләәән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаẓәбилләәһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүʼминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләẓиинәт-тәкау, вәл-ләẓиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйẓү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалаллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иẓәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйẓү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә гәззә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлиииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и

минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүүн. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмас-сыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләү.

**Иң соңыннан, «Әгуүзү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән, [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*14 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Мөхәррам ае фазыйләте

Барча мактауларыбыз безне юктан бар иткән, безгә ризык биргән һәм безне туры юлга юнәлдергән Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде, сөйләгән вәгазьләребез, кылган гыйбадәтләребез файдалы булса иде.

Мөселман календареның беренче ае булган мөхәррам ае җитү белән яңа ел башлана. Быел мөхәррам ае керү белән һиҗри буенча 1445 ел башланып китәчәк.

Ислам дине барлыкка килгән чорда мөселманнарның үз календаре булмый әле һәм шул сәбәпле мәшәкатьләр килеп туа. Сәхабәләр үзара киңәшләшкәннән соң, елны һиҗрәт, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күчү вакыйгасыннан саный башларга кирәк, дигән фикергә киләләр, чөнки нәкъ менә һиҗрәттән соң дин тотучылар тормышында яңа этап башлана, Мәдинәдә, кечкенә булса да, беренче Ислам дәүләте барлыкка килә, дөньяда беренче мәчет төзелә.

Беренче сәхабәләрнең һиҗрәте дә һәрберебез өчен ныклык һәм күркәм үрнәкнең мисалы булып тора. Сәхабәләр туган йортларын, туганнарын, якыннарын, малларын калдырып, Аллаһы ризалыгы өчен дип, динебез Исламны куәтләү ниятеннән нурлы, Мәдинә шәһәренә күченәләр.

Һиҗри елның иң беренче, харам айларыннан булган ае – ул мөхәррам ае. Шушы айның фазыйләтен һәм аның изге гамәлләрен күрсәтеп, Аллаһының Расүле: «Рамазаннан соң иң хәерле ураза – Аллаһының ае булган мөхәррам уразасы»[1], – дигән.

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – хак дин».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Әбү Бәкрат радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен китергән: «Елда унике ай бар. Аларның дүртесе тыелу айлары. Өчесе рәттән килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм дүртенчесе – җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан арасында булган раҗәб ае»[1].

Харам айлары тыелу айлары дип атала. Әгәр дә ел буена гөнаһ, харам гамәлләр эшләү тыелган икән, ошбу дүрт айда аларның харамлыгы, гөнаһлылыгы тагы да арта. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә аятьне дәвам итеп:

فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез»**, – дип әйтә.

«Әт-Тәүбә», 9:36

Хөрмәтле дин кардәшләребез, белүебезчә, әгәр берәр нәрсә Аллаһының Үзенә бәйләнеп куелса, аның дәрәҗәсе һәм фазыйләте дә арта. Шуңа күрә дә Аллаһының Расүле мөхәррам аен Аллаһының ае дип атап, ошбу айның фазыйләтен һәм дәрәҗәсен күтәрде. Димәк, бу ай Аллаһы өчен сөекле, бу айда эшләнелгән изгелекләр өстенрәк, бу айда эшләнелгән гөнаһлар авыррак булып тора.

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Мөхәррам аенда сөннәт булып торган гамәлләрнең берсе – ул ураза тоту.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә өчен Рамазан аенда тотылган уразадан соң иң хәерлесе – мөхәррам аеныкы», – дип әйткән. Монда ул мөхәррам аеның өстенлеген билгеләп үтә.

Мөхәррам аеның 10 нчы көне – иң мөбарәк, олуг көне. Бу көн Гашурә көне дип атала. Гашурә көнендә ураза тоту Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Хәбәр ителгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, андагы яһүдиләрнең бу көндә ураза тотуларын күргән. Моның сәбәбен сорагач, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу көнне Муса галәйһиссәламнең халкы белән фиргавеннән котылуын һәм фиргавеннең һәлак ителүен әйткәннәр. Моңа каршы Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Безнең Муса галәйһиссәламгә хакыбыз зуррак һәм без аңа якынрак» – дип, шушы көндә мөселманнарга да ураза тотарга кушкан.

Әмма Рамазан аенда ураза тоту фарыз булгач, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә Гашурә көнендә ураза тотарга боеруны туктаткан. Шулай да Гашурә көне уразасы сөннәт гамәл булып калган. Моннан тыш, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, яһүдиләргә охшамас өчен, Гашурә көне уразасы алдыннан яки артыннан бер көн кушып ураза тотарга кушкан. Димәк, мөхәррамның 9 нчы һәм 10 нчы көннәрендә яисә мөхәррамның 10 нчы һәм 11 нче көннәрендә ураза тоту дөрес була.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөхәррам аен Аллаһы ае дип билгеләве аңа дәрәҗә бирә. Бу сүзләр изгелекләр кылып, гыйбадәтләребезне арттырыр өчен җитәрлек сәбәп булырга тиеш. Галимнәр иҗтиһады буенча, тыелган айлар – ул бәрәкәтле айлар, ягъни Раббыбызның бәрәкәт урнаштырган айлары булып тора.

Нәрсә соң ул бәрәкәт? Бәрәкәт – ул Аллаһының зур нигъмәте, бүләге. Бәрәкәт булганда аз гына акча да җитәрлек була, ике кешелек ризык та өч

кешегә җитә, аз гына вакытта да күп эшләребезне эшләргә өлгереп була. Шуңа күрә дә һәрнәрсәнең бәрәкәтен, бәрәкәтле булуын сорарга тиешбез. Мондый бәрәкәтле айлар бүгенге тынгысыз, вакыт җитмәгән тормышта аеруча да зур бүләк булып тора. Шуңа да без бу айларның бәрәкәтен алырга тырышыйк, бу айларны «Аллаһының ае» дип, олылап уздырыйк, гамәл-гыйбадәтләребезне арттырыйк.

Тиздән мөхәррам аена керәбез. Мөхәррам ае мөселманча яңа ел башлану ул, дидек. Димәк, без тормышыбызны яңадан, яңа биттән башлыйбыз. 1445 елга аяк басканда үткән елда кылган гамәлләребезгә күз салу, аларга бәя бирү гадәтен кертсәк иде. Һәрбер кешегә үз-үзенә хисап бирү мөһим. Тугры хәлиф Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Сезгә хисап кылынганчы, үз-үзегезгә хисап кылыгыз. Гамәлләрегез үлчәнгәнче, үзегез гамәлләрегезне үлчәгез», – дип әйткән.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабуллардан әйләп, булган хата-кимчелекләребезне, гөнаһларыбызны гафу итсә иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*
*Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге*
*«Ал Таң» мәчете имамы*

*21 нче июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Адәм балаларына ихтыяр көче бирелгән

Барча мактаулар һәм сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Аллаһы Раббыбыз җирләрне, күкләрне яраткан, кояшы җылытып тора, сулар һавасы, эчәр сулары чиксез. Бу нәрсәләрне беркем дә инкяр итә алмый. Бу хакта Раббыбыз Коръәндә дә кабатлап, искә төшереп тора:

أَلَمْ تَرَوْا أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَأَسْبَغَ عَلَيْكُمْ نِعَمَهُ ظَاهِرَةً وَبَاطِنَةً

**«Күрмәдегезме, Аллаһы күкләрдә булганнарны һәм җирдә булганнарны сезнең [файдалануыгыз] өчен буйсындырды, [күркәм кыяфәт, буй-сын һәм әгъзаларыгызның бөтенлеге булып] күренгән һәм [акыл, күңел, аңлау кебек] яшерен булган нигъмәтләрне дә сезгә бирде».**

«Локман», 31:20

Бу нәрсәләр, чыннан да, Аллаһының олуг Кодрәт иясе икәнен раслый. Кеше күпме генә тырышса да, күпме генә газаплanса да, кечкенә генә черкине дә ясап, очыртып җибәрә алмаячак.

Әгәр төнге күк йөзенә карасак, чиксез сандагы йолдызларны күзәтергә була. Алар, һичшиксез, үзлегеннән генә пәйда булмаган. Кемдер аларны яраткан да, күк йөзенә элеп куйган. Мәктәптә өйрәнелә торган физика фәненнән генә дә беләбез: бер предмет та үзлегеннән генә барлыкка килми. Моның өчен ниндидер энергия чыганагы кирәк. Безгә шуларны аңлатыр өчен, Аллаһы Тәгалә «Йәсин» сүрәсендә болай дип әйтә:

إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَن يَقُولَ لَهُ كُن فَيَكُونُ

**«Ул берәр нәрсәне теләгән чакта, Ул аңа «Бул!» дип әйтүгә, ул шунда ук бар була».**

«Йәсин», 36:82

Димәк, акылга сыймаслык зур галәмнәрне, баһадир тауларны, чиксез сулыкларны күреп, гаҗәпләнәсе дә юк. Раббыбызга боларны бар кылуның бер авырлыгы да юк икән. Аңа бу гамәлләрне эшләү бик җиңел.

Бәлки кешегә үзенә карап, үзе белән горурланырга, сокланыргадыр? Тагын сорау туа: ничек инде мин үз-үземә сокланыйм? Җир шары белән генә чагыштырганда да, мин бер нокта кебек кенә. Шуның өстәвенә зәгыйфь бер затмын. Моны да инкяр итеп булмый. Адәм баласы зәгыйфь, мохтаҗ итеп яратылган. Ул ризыкка, суга, акчага, киемгә, игътибарга һәм башкаларга мохтаҗ. Адәм баласы туганнан алып соңгы сулышына кадәр теләнче ролен башкаручы бер зат инде ул. Шуңа да карамастан, бездә күпләр кадерен белми торган нәрсә бар – ул да булса ирек, сайлау иреге. Аллаһы безгә шушы нәрсәне зур бүләк итеп биргән. Мисал итеп фәрештәләрне алырга була. Раббыбызның олуг фәрештәләре бар. Җир өстен авыллары, шәһәрләре белән куптарып алып, әйләндереп сала торганнары, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән җил-давыллар куптарып, бар нәрсәне дә һәлак итә торганнары, көндез, кич, төнлә булуына карамастан, килеп җанны алучысы да бар. Ләкин аларның, Адәм баласыннан аермалы буларак, гамәл иреге юк. Алар Раббыларының әмереннән башка берни дә эшли

алмый. Ә безгә Раббыбыз зур нигъмәт итеп акыл һәм гамәл ирегe биргән. Бәлки мөселман бәндәсе, Аллаһы Тәгаләнең әмерен тулысынча үтәгән вакытта, Раббысы каршында булган барлык җанлы, җансыз мәхлүкатлардан хәерлерәктер?!

Коръәндә Аллаһы Тәгалә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ

**«Без кешене иң күркәм сурәттә яраттык»,** – дип әйтә.

«Әт-Тин / Инҗир», 95:4

Дәвам итеп алдагы аятьтә:

ثُمَّ رَدَدْنَاهُ أَسْفَلَ سَافِلِينَ

**«Шуннан соң [бу шәкелдә күркәм яратылыш нигъмәтенә шөкер итмәгәне өчен] аны [җәһәннәм әһеленнән итеп, күрер күзгә] түбәннәрнең иң түбәне булганга кайтардык»,** – ди.

«Әт-Тин / Инҗир», 95:5

Димәк, Раббыбыз безне күркәм сурәттә яратты, акыл, гамәл ирегe бирде һәм соңыннан, әлеге аятьтән аңлавыбызча, дөрес юлны сайламаганыбыз өчен, җәзага тартачак. Шуңа да, ни өчен без үз-үзебез белән горурланырга тиеш соң? Моның өчен сәбәп юк кебек. Аллаһы Тәгаләнең, кеше белән җеннән кала, бер мәхлүкаты да җәһәннәмгә эләкмәячәк бит.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

إِنَّا عَرَضْنَا الْأَمَانَةَ عَلَى السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَالْجِبَالِ فَأَبَيْنَ أَن يَحْمِلْنَهَا وَأَشْفَقْنَ مِنْهَا وَحَمَلَهَا الْإِنسَانُ ۖ

**«Без ул әманәтне күкләргә, җиргә һәм тауларга тәкъдим иттек, ләкин алар аны өсләренә алудан баш тарттылар һәм аңардан**

**курыктылар. Кеше исә аны өстенә алды [әмма күпчелеге аңа хыянәт итте]...»** – дип әйтә.

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:72

Димәк, Аллаһы Коръәндә булган кануннарны күкләргә, җиргә һәм тауларга тәкъдим иткән. Алар кыенлыгыннан куркып калып, зур җаваплылыкны үз өсләренә аласылары килмәгән.

Раббыбыз болай дип әйтә:

لَوْ أَنزَلْنَا هَٰذَا الْقُرْآنَ عَلَىٰ جَبَلٍ لَّرَأَيْتَهُ خَاشِعًا مُّتَصَدِّعًا مِّنْ خَشْيَةِ اللَّهِ ۚ

**«Әгәр дә Без бу [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] Коръәнне бер тауга иңдергән [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] булсак, син аны Аллаһыдан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:21

Әйе, адәм баласына бирелгән йөкләр тауга иңдерелгән булса, ул җаваплылыгыннан куркып, икегә ярылган булыр иде. Әмма адәм баласы шундый олуг вазифаны үз өстенә алды, ярылмады да, курыкмады да. Бары тик мөселман кешесенең күңеле генә авыр йөкне күтәрә алды. Адәм баласы әгәр кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсә, Аллаһы Тәгалә каршында барлык мәхлүкатлардан да дәрәҗәлерәк булачак. Ә инде бирелгән гамәл иреген дөрес булмаган, Ислам диненә каршы килә торган юлда кулланып гомер итсә, ләгънәте төшкән, иң түбән затка әвереләчәк. Димәк, үзенең гамәлләре сәбәпле, адәм баласы яисә җәннәт түрендә, яисә җәһәннәмнең төбендә була ала.

Адәм баласының акылы бар, иреге бар, һәм нинди юлны сайлавы аның ихтыярында. Кыямәт көнендә һәр җан иясе, гамәленә карап үзенә тиешле бүләген алачак. Беркем дә нахак яла ягылып түбәнсетелмәс, чөнки

адәм баласы үзе теләп җаваплылыкны алды. Шуңа да: «Мин ишетмәдем, белмәдем», – дип аклана алмаячак. Моңа да дәлил бар:

وَإِذْ أَخَذَ رَبُّكَ مِن بَنِي آدَمَ مِن ظُهُورِهِمْ ذُرِّيَّتَهُمْ وَأَشْهَدَهُمْ عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ أَلَسْتُ بِرَبِّكُمْ ۖ قَالُوا بَلَىٰ ۛ شَهِدْنَا ۛ أَن تَقُولُوا يَوْمَ الْقِيَامَةِ إِنَّا كُنَّا عَنْ هَٰذَا غَافِلِينَ

**«Раббың Адәм [нәселеннән, турыдан-туры аңардан яратачак балаларын, аның] балаларыннан [исә] аларның аркаларыннан нәселләрен чыгарды һәм [ул нәселләргә тормыш, аңлау һәм сөйләшү сәләте биреп] аларны үз-үзләренә шаһит тотты: «Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» Алар исә: «Әлбәттә [Раббыбыз Син генәсең]! Без [Синнән башка Раббыбыз булмаганына һәм Синең берлегеңә] шаһитлык итәбез» – диделәр. [Аллаһы аны] Кыямәт көнендә сез: «Без моннан хәбәрсез идек», – дип әйтмәвегез өчен [эшләде]».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:172

Аллаһы Тәгалә җаннарны халык кылганнан соң, аларны җыеп: «Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» – дип сораган. Алар: «Әйе! Без моңа шаһитлык итәбез», – дигәннәр. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларның ризыкларын, әҗәлләрен һәм башларына киләчәк бәлаләргә кадәр һәрнәрсәләрен язган. Моннан тыш, алардан Үзенә гыйбадәт кылып, Аңа һичбер нәрсәне ширек кушмаячаклары турында сүз алган һәм ризыкларына кәфил[1] булган, шуннан аларны Адәм галәйһиссәләмнең сыртына кайтарып куйган. Шул көнне Аллаһы Тәгаләгә сүз биргән нәселләрнең һәммәсе дә тумыйча, Кыямәт көне башланмаячак.

Әйе, дөньяга җибәргәнче Аллаһы Тәгалә һәр бәндәдән сүз алган. Һәрбарчабыз да Раббыбызга: «Син минем Раббым, бары тик Синең

[1] Кәфил булу – бирәү өчен җаваплылыкны үз өстеңә алу, ышаныч күрсәтү, тәэмин итү.

кануннарың буенча гына яшәячәкмен», – дип сүз биргән. Ләкин аны беркем дә хәтерләми, ул сызылып атыла. Ә инде җан тәнне ташлап чыгып киткәннән соң, биргән вәгъдәләр искә төшә. Кеше элек күрмәгән фәрештәләрне, җеннәрне күрә башлый һәм Аллаһы Тәгалә белән сөйләнелгән сүзләр дә акылга янәдән кайта. Әгәр дә бу вәгъдәләр, сүзләр онытылмаган булса, җир йөзендәге барлык халык та мөселман булыр иде. Шулай ук үлем белән терек-лекне сынау һәм кайсыбыз күркәм гамәлләре белән Аллаһыга итагатьлерәк дигән сүзләрнең мәгънәсе дә булмас иде. Болар барысы да бары тик сынау өчен генә шулай эшләнелә. Имтиханда дөрес җавапларны карый алмаган кебек, тормышыбыз да олы бер имтихан. Җаныбыз Раббыбыз хозурына күчкәннән соң гына имтиханның нәтиҗәсен барчабызның да каршысына китереп куячаклар. Коръәндә болай дип әйтелә:

إِنَّهُۥ كَانَ ظَلُومًا جَهُولًا

**«Һичшиксез, ул [кешеләрнең бик күбесе] залим һәм [эшнең нәтиҗәсен белми торып аңа алынган] надан булды».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:72

Бу аять ни өчен кешенең үз өстенә шундый зур вазифаны алуының сәбәбен аңлата. Әгәр Коръән тауларга, күкләрнең өстенә иңгән булса, алар берсүзсез буйсынырлар иде, ә адәм баласы буйсынмады. Шуңа күрә дә адәм баласы бары тик үзен генә гаепли ала, һәр җан үзе өчен генә җавап тотачак.

Аллаһы Раббыбыз өстебезгә йөкләнелгән вазифаларны тулысынча үтәргә көч бирсә иде. Раббыбызның рәхмәтен өмет итеп кылган барлык гамәл-гыйбадәтләребез кабуллардан булып, ике дөнья бәхетенә ирешүдә сәбәпче булса иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*28 нче июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гашурә көне фазыйләтләре

Барча мактаулар һәм дә сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Билгеле бер фазыйләтле көннәрнең һәм айларның булуы – Аллаһының бәндәләренә биргән нигъмәтләренең берсе ул. Шушы вакытларда Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларны арттырып бирә һәм изге гамәлләрнең дәрәҗәсен күтәрә. Күптән түгел генә мөбарәк хаҗ айлары тәмамланды, һәм чираттагы ай, Аллаһының ае – мөхәррам ае да килеп җитте.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Рамазан аеннан соң иң күркәм ураза – Аллаһының аенда тотылган ураза, сез аны «мөхәррәм ае» дип атыйсыз. Фарыз намаздан соң иң яхшы намаз – нәфел булган, төнлә укыла торган тәһәҗҗөд намазы».[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөхәррам аен «Аллаһының ае» дип атавы, бу айның мөбарәк һәм фазыйләтле булуына дәлил булып тора. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә Үзенең яраткан нәрсәләреннән кайберләрен сайлап, аларга үзенчәлекләр бирә һәм аларның дәрәҗәсен күтәрә.

Хәсән Әл-Басри рахимәһуллаһи: «Чыннан да, Аллаһы Тәгалә елны тыелган айдан башлап, тыелган ай белән тәмамлады. Рамазан аеннан соң, тыю ягыннан, бу айдан да зуррак ай юк», – дип әйткән.

[1] Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

Бу айда бер көн бар, шул көндә мөһим вакыйга булган: ачык җиңү, хакыйкать ялганнан өстен чыккан. Бу көндә Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламне һәм аның халкын коткарып, фиргавенне һәм аның гаскәрен суга батырган. Бу көннең зур фазыйләте бар: ул мөхәррам аеның унынчы көне – «Гашурә көне» дип атала.

Гашурә көненең һәм ул көндә ураза тотуның фазыйләте. Күп кенә сахих хәдисләрдә Гашурә көненең фазыйләте һәм ул көндә ураза тоту хакында әйтелә. Аларның кайберләрен карап үтик.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән Гашурә көне хакында сораганнар. Ул: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм көннәрдән Гашурә көненең һәм айлардан Рамазан аеның дәрәҗәсен алырга омтыла иде», – дигән мәгънәдәге сүзләр әйткән.[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә булганда Гашурә көнендә ураза тоткан, ләкин башкаларга ураза тотарга кушмаган. Мәдинәгә килеп җиткәч, ул китап әһелләренең ураза тотуын һәм бу көнне зурлавын күргән. Моннан соң ул башкаларны да шушы көндә ураза тотуга өндәгән.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән болай дип хәбәр ителә: Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килеп, андагы яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотканын күргәч: «Сез ураза тоткан көн нинди көн ул?» – дип сораган. Алар: «Бу – бөек көн. Бу көндә Аллаһы Тәгалә Мусаны һәм аның халкын коткарды, фиргавенне һәм аның гаскәрен батырды. Муса бу көнне Аллаһыга шөкер йөзеннән ураза тотты, шуңа күрә без дә бу көнне ураза тотабыз», – дип җавап биргән. Шуннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бездә Мусадан үрнәк алырга хокуклар күбрәк һәм без сезгә караганда аңа лаеклырак»[2], – дигән.

Тик Рамазан ае уразасы фарыз булгач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә бу көндә ураза тотарга боеруны туктата.

---

1 Имамнар Әл-Бохари һәм Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

2 Шунда ук.

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән болай дип китерелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашурә көнендә ураза тотты һәм башкаларга да ураза тотарга кушты, ләкин Рамазанда ураза тоту фарыз булгач, ул аны калдырды, ягъни Гашурә көнендә ураза тотарга боеруны туктатты һәм ул нәфел ураза булды»[1].

Ләкин Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Рамазан аенда ураза тоту фарыз булганнан соң да, Гашурә көнендә ураза тотуын дәвам итә. Габдулла бине Муса радыяллаһу ганһе болай дип риваять кылган: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашурә көнендә ураза тотуны башка көннәрдә ураза тотудан, ә Рамазан аенда ураза тотуны Гашурә көнендә ураза тотудан өстен күрде»[2].

Бер сүз белән әйткәндә, күп хәдисләр нигезендә Гашурә көнендә ураза тоту Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте булып тора һәм кеше бу көнне ураза тоту белән, иншәАллаһ, зур әҗер-савапка лаек булачак.

Башка хәдис буенча, Гашурә көнендәге ураза алдагы яки киләчәк көн уразасы белән кушылырга тиеш, ягъни: уразаны мөхәррамның 9 нчы һәм 10 нчы көннәрендә яки мөхәррамның 10 нчы һәм 11 нче көннәрендә тотарга кирәк. Өстәмә ураза тотуның сәбәбе шунда: яһүдиләр Гашурә көнендә генә ураза тотканга күрә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарның ураза тоту рәвеше яһүдиләрдән аермалы булуын теләгән. Шуңа күрә ул мөселманнарга Гашурә көне уразасын бер генә көн итеп тотмаска кушкан.

Кайбер хәдисләр Гашурә көненең тагын бер үзенчәлеген күрсәтә: бу көнне кешегә үз гаиләсенә карата аеруча да юмарт булырга һәм аларны, башка көннәргә караганда, тәмлерәк, сыйлырак ризык белән тукландырырга киңәш ителә.

1 Имамнар Әл-Бохари һәм Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

2 Шунда ук.

Әбү Катәдә риваять итүенчә, бер кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Гашурә көнендә ураза тоту турында сораган һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гашурә көнендә ураза тоту – Аллаһы каршында соңгы бер ел эчендә кылган гөнаһларның кичерелүенә сәбәпче булыр дип өметләнәм»[1], – дип җавап биргән.

Ягъни, Гашурә көнендә тотылган ураза узган елда кылган гөнаһларның кичерелүенә сәбәпче булырга мөмкин. Шуңа да мондый мөмкинлектән файдаланып калыйк, җәмәгать.

Аллаһы Тәгалә безгә ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп итсен, кылган гөнаһ вә хата-кимчелекләребезне Үзенең чиксез Рәхмәте белән гафу кылсын иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,*
*«Иман Нуры» мәчетенең икенче имамы*

---

[1] Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

*4 нче август вәгазе,*

*мөхәррам аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Сыер кыйссасының хикмәте

Барча мактауларыбыз безне юктан бар иткән, безгә ризык биргән һәм безне туры юлга юнәлдергән Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде, сөйләгән вәгазьләребез, кылган гыйбадәтләребез файдалы булса иде.

Коръәни Кәрим 114 сүрәдән тора. Аларның иң кыскасы өч аятьлек «Әл-Кәүсәр» сүрәсе булса, ә иң озыны 47 биттән торган, 286 аятьлек «Әл-Бәкара» сүрәсе. Шушы зур сүрәдә Коръәндәге иң бөек аять – «Аятел-Көрси» бар, биредә Гареш астындагы хәзинәдән алып бирелгән «Әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы ике бөек аятьләре бар.

«Әл-Бәкара» сүзе «Сыер» дип тәрҗемә ителә. Бу сүрәнең шулай аталу сәбәбе Бәни Исраил халкында булган сыер кыйссасы белән бәйле. Бу кыйсса 67–74 нче аятьләрдә килә.

Муса галәйһиссәлам заманында бер бик бай кеше яши. Бу карт кешенең үз балалары булмый. Аның турыдан-туры варисы буларак бер якын туганы була. Бу ир, абыйсының мирасын тизрәк алу өчен, аны үтерә һәм үле гәүдәсен башка бер кабиләнең җирләрендә ташлап калдыра. Иртә белән мәет табылгач, ике кабилә арасында зур гауга чыга, хәтта алар кылычларына хәтле ябышалар. Араларында берсе, үтерүчене ачыклар өчен, Муса галәйһиссәлам янына барырга тәкъдим итә.

Монда шуны әйтәсе килә: кешеләр кайсы гына заманда яшәсәләр дә, биш мең ел элек яшәдеме ул, әллә хәзерге кешеме, араларында бернинди аерма да юк. Бәлки аларның гадәтләре, аңнары икенчедер, әмма кешеләр үзгәрми. Элек тә мирасны комсызланып, сугышып бүлешкәннәр,

хәзер дә нәкъ шулай. Элек тә явызлар һәм изгеләр булган, хәзер дә шулай. Кайберәүләр: «Ислам шәригате урта гасырлар өчен яраган, хәзер кешеләр дә, замана да башка», – дип әйтә. Юк, кешеләр шул ук. Шуңа да шәригать тә һәр заманга яраклы булган мәңгелек канун ул.

Кыйссага кайтыйк. Бу бәхәс килеп чыккач, халык мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, Муса галәйһиссәлам янына килә. Муса галәйһиссәлам Раббыбызга мөрәҗәгать иткәннән соң, алган җавапны кавеменә әйтә. Коръәндә бу хакта болай диелә:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تَذْبَحُوا بَقَرَةً ۖ قَالُوا أَتَتَّخِذُنَا هُزُوًا ۖ قَالَ أَعُوذُ بِاللَّهِ أَنْ أَكُونَ مِنَ الْجَاهِلِينَ

**«Һичшиксез, Аллаһы сезгә бер сыер чалыргa боера», – диде дә, алар: «Син безне мыскыл итәсеңме әллә?» – дигәннәр иде. [Муса [галәйһиссәлам] исә:] «Мин [сезнең кебек гамьсез-ваемсыз] җаһилләрдән булудан Аллаһыга сыенам», – диде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:67

Әйе, Муса галәйһиссәлам халкына: «Үтерүчене белү өчен, сыер чалырга кирәк», – диде. Әмма халкы: «Нигә син безне мыскыл итәсең? Без синнән үтерүченең кем икәнен сорыйбыз, ә син безгә, сыер чалыгыз, дип көләсең»,– дип карыштылар. Каршылык күрсәтүләре белән Аллаһының Расүленә карата әдәпсезлек һәм дорфалык күрсәттеләр. Муса галәйһиссәлам бу хәлләрне күреп: «Сезнең кебек гамьсез-ваемсыз җаһилләрдән булудан Аллаһыга сыенам», – дип әйтте, чөнки Аллаһыдан ерак булган, надан, җаһил кешеләр генә башкаларны мыскыл итеп, түбәнсетеп, көлеп йөри.

Әмма бу әмер Муса галәйһиссәламнең сүзе түгел, ә Аллаһының әмере иде. Күпме генә карышсалар да, соңрак халык бу эшкә күнде һәм сыер чалырга булды. Монда да мәшәкать килеп туды: аларга теләсә нинди бер сыерны чаласы иде дә, тик алар сораулар биреп, эшләрен авырайтып

бетерделәр. Янәсе, алар төгәллек кертергә теләделәр. Башта алар Муса галәйһиссәламнән:

قَالُوا ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّن لَّنَا مَا هِيَ ۚ

**«Безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның [яше һәм сыйфатлары] нинди булганын аңлатсын»,** – дип сорадылар.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:68

Муса галәйһиссәлам аларга:

قَالَ إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا بَقَرَةٌ لَّا فَارِضٌ وَلَا بِكْرٌ عَوَانٌ بَيْنَ ذَٰلِكَ ۖ

**«Һичшиксез, Ул [Раббым]: «Ул сыер бик карт та, бик яшь тә булмасын, болар арасындагы [урта] яшьләрдә [булсын]», – диде»,** – дип хәбәр бирде.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:68

Әмма бу җавап та аларны канәгатьләндермәде. Соңрак алар:

ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّن لَّنَا مَا لَوْنُهَا ۚ

**«Безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның төсе нинди булганын ачыкласын»,** – диделәр.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:69

Муса галәйһиссәлам аларга мондый җавап җиткерде:

قَالَ إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا بَقَرَةٌ صَفْرَاءُ فَاقِعٌ لَّوْنُهَا تَسُرُّ النَّاظِرِينَ

**«[Раббым]: «Караучыларны шатландыра торган сап-сары төсле сыер», – дип әйтте».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:69

Моннан соң бу кешеләр Муса галәйһиссәламгә килеп:

ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّن لَّنَا مَا هِيَ إِنَّ الْبَقَرَ تَشَابَهَ عَلَيْنَا وَإِنَّا إِن شَاءَ اللَّهُ لَمُهْتَدُونَ

**«Безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның нинди [тазамы, арыкмы] икәнлеген аңлатсын, чөнки [сары һәм урта яшьтәге] сыерлар бер-берсенә охшаш. Һичшиксез, без, әгәр Аллаһы теләсә, [эзләгән сыерны очрату мәсьәләсендә] туры юлны табарбыз»,** – диделәр.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:70

Бу үтенечләренә каршы аларга:

إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا بَقَرَةٌ لَّا ذَلُولٌ تُثِيرُ الْأَرْضَ وَلَا تَسْقِي الْحَرْثَ مُسَلَّمَةٌ لَّا شِيَةَ فِيهَا ج

**«Шиксез, ул – [авыр эшләрдә кулланылмаган һәм] җир сукалап, иген сугарып эшләгән түгел, [кимчелекләрдән пакь] сау-сәламәт һәм бернинди [башка] төс катнашмаган сыер»,** – дигән хәбәр килде.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:71

Бу җавапны ишеткәч кенә алар:

الْآنَ جِئْتَ بِالْحَقِّ

**«Менә хәзер син хак [мәгълүмат] китердең инде»,** – диделәр.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:71

Ни гаҗәп, Муса галәйһиссәлам аларга инде башта ук: «Теләсә кайсы сыерны чалыгыз», – дип әйткән иде. Әмма кирәкмәгән, артык сораулар биреп, алар үз эшләрен авырайтып бетерделәр. Нәтиҗәдә мондый сыерны озак эзләгәннән соң гына, меңләгәне арасыннан, ниһаять, тиешлесен таптылар.

Әмма сыерның хуҗасы аларга бик зур бәя куйды һәм сатулаша торгач, алар сыерны үз авырлыгындагы алтынга сатып алырга мәҗбүр булдылар. Бу халык сораулар белән эшләрен шулкадәр авырайтты ки, хәтта сыерны чалып тормыйча, бу эшкә кул селтәргә дә әзер иделәр. Коръәндә бу хакта:

فَذَبَحُوهَا وَمَا كَادُوا يَفْعَلُونَ

**«... һәм аны чалдылар. Әмма алар үтәмәүгә бик якын иделәр»,** – диелә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:71

Сыерны чалгач, бу кешеләргә:

اضْرِبُوهُ بِبَعْضِهَا ۚ

**«Аның берәр әгъзасы белән аңа [мәеткә] сугыгыз»,** – дип әмер ителә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:73

Сыерның бер өлеше белән мәеткә тидергәч, ул терелә һәм үтерүченең кем икәнлеген әйтеп, яңадан үлә. Шулай итеп Аллаһы Тәгалә аларга Үзенең кодрәтен күрсәтте, мәетнең терелүе аларга бер могҗиза булды һәм үтерүченең дә кем икәнлеге ачыкланды. Бу хакта Коръәндә болай диелә:

كَذَٰلِكَ يُحْيِي اللَّهُ الْمَوْتَىٰ وَيُرِيكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ

**«[Ий терелүне инкяр иткән кеше!] Аллаһы әнә шулай [тиңсез бер кодрәт белән] үлеләрне терелтә һәм могҗизаларын сезгә күрсәтә, бәлки, сез аңларсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:73

Бу могҗиза аларның йөрәкләрен йомшартырга тиеш иде, әмма аларның йөрәкләре киресенчә катты. Күрәсең, Аллаһының Расүле Муса галәйһиссәламгә карышулары, сораулар биреп эшне авырайтулары, сыер өчен бик зур

бәя түләүләре аларны Аллаһыдан ерагайткан. Соңрак Аллаһы Тәгалә бу хакта болай дип әйтә:

ثُمَّ قَسَتْ قُلُوبُكُم مِّن بَعْدِ ذَٰلِكَ فَهِيَ كَالْحِجَارَةِ أَوْ أَشَدُّ قَسْوَةً ۚ وَإِنَّ مِنَ الْحِجَارَةِ لَمَا يَتَفَجَّرُ مِنْهُ الْأَنْهَارُ ۚ وَإِنَّ مِنْهَا لَمَا يَشَّقَّقُ فَيَخْرُجُ مِنْهُ الْمَاءُ ۚ وَإِنَّ مِنْهَا لَمَا يَهْبِطُ مِنْ خَشْيَةِ اللَّهِ ۗ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا تَعْمَلُونَ

**«Шуннан бу [үлекнең терелеп сөйләшүе кебек ап-ачык бер могҗиза вакыйгасы] булганнан соң, күңелләрегез таш кебек катты яки тагы да катырак булды. Һичшиксез, ташлар арасында да чишмәләр бәреп чыкканы бар; һичшиксез, алар [ташлар] арасында да ярылып, эченнән су чыкканнары бар һәм, һичшиксез, Аллаһыдан курыкканнары сәбәпле, [югарыдан түбәнгә] төшкәннәре бар. Аллаһы исә сезнең кылганнарыгыздан гафил түгел».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:74

Аллаһы Тәгалә аларның күңелләрен каты таш белән чагыштырды. Таш араларыннан да сулар бәреп чыга, ташлар да тетрәп ярыла, шуның белән аларның кирелекләре тагы да көчәйде. Каткан йөрәк Аллаһыны искә алырга теләми, Аллаһыдан курыкмый. Бу йөрәк гөнаһка тарта. Коръәндә:

أَفَمَن شَرَحَ اللَّهُ صَدْرَهُ لِلْإِسْلَامِ فَهُوَ عَلَىٰ نُورٍ مِّن رَّبِّهِ ۚ فَوَيْلٌ لِّلْقَاسِيَةِ قُلُوبُهُم مِّن ذِكْرِ اللَّهِ ۚ أُولَٰئِكَ فِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ

**«Аллаһы күкрәген Ислам өчен киңәйткән һәм шул сәбәпле ул Раббысыннан [килгән] бер нур [һәм илаһи бер рәхмәт] эчендә булган кешеме [Аллаһының фитратын бозганы өчен күкрәге тарайган кешегә тиңме] соң! Аллаһының зикеренә [йомшак булу урынына Аның исемен һәм аятьләрен ишеткән вакытта нәфрәтләре артып,**

**күңелләре] каты булганнарга ни үкенеч! Алар ап-ачык бер адашу эчендә»,** – дип әйтелә.

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:22

Пәйгамбәребезнең сәхабәсе Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтүенчә, алар кабиләдәшләренең үтерүче икәнен таныргa теләмәделәр һәм бу терелгән мәетнең сүзләрен ялганга чыгардылар. Шул сәбәпле, бу кабилә халкының йөрәкләре таш кебек катты һәм хакны кабул итмәс булды.

Бу кыйссадан төп дәрес булып, күп сораулар бирмичә, Аллаһының әмерләренә буйсынырга кирәклеге тора. Бу очракта Аллаһы кешенең эшен җиңеләйтә һәм аңа гыйбадәтен үтәүдә ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә, Мусаның халкыннан аермалы буларак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре хакында болай дип әйтә:

سَمِعْنَا وَأَطَعْنَا ۖ غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ

**«[Боерыгыңны] Ишеттек, [әмереңә] итагать иттек. Ий Раббыбыз, мәгъфирәтеңә сыенабыз! [Үлгәннән соң] Кайтуыбыз – тик Сиңа!» – диделәр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:285

Күп сораулар бирүне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә тыя торган булды һәм моңа ачулана иде. Ул күп сораулар бирелгәч, Аллаһыдан җавабы авыр булып, безгә дин тотуның катлаулы булуыннан курыкты.

Шулай ук сорау биргәч, җавабы кешене борчу-кайгыга сала икән яки аның тормышын боза икән, яки кешеләрне дошманлаштыра икән, бу кеше аңа әлеге сорауны бирергәме, әллә белмәү тынычрак булырмы, дип уйлансын иде. Кайберәүләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Минем чын атам кем?» яки «Минем вафат булган ата-анам хәзер кайда?» – дип сораулар бирәләр иде. Ләкин сорауларына алынган җавап аларны борчуга сала

иде. Шуңа күрә Расүлебез мондый сорауларга ачулана торган булды. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَسْأَلُوا عَنْ أَشْيَاءَ إِن تُبْدَ لَكُمْ تَسُؤْكُمْ

**«Ий иман китерүчеләр! Ачыклангач, [соңыннан] сезгә бик авыр булачак нәрсәләр турында [Пәйгамбәрдән] сорамагыз».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:101

Шулай ук файдасы булмаган, мәгънәсез сораулар бирү дә ярамыйдыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы сезгә өч эшне мәкруһ кылды: имеш-мимешләр тарату, малны әрәм итү һәм күп сораулар бирүне», – дигән[1].

Әмма белемгә омтылып, хаклыкны, динне белү өчен сораулар бирү әмер ителә. Бу бирелгән сораулар хәтта Коръәндә дә искә алына, мәсәлән:

يَسْأَلُونَكَ عَنِ الْأَهِلَّةِ ۖ

**«Синнән яңа чыккан айлар турында сорыйлар»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:189

يَسْأَلُونَكَ مَاذَا يُنفِقُونَ ۖ

**«[Расүлем!] [Байлар] Синнән [малларын] ничек сарыф итәргә кирәклеген сорыйлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:215

Яки:

وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْمَحِيضِ ۖ

**«[Ий Расүлем!] Синнән күрем [хәлендәге хатыннар белән ничек булырга кирәклеге] турында сорыйлар»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:222

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

يَسْأَلُونَكَ مَاذَا أُحِلَّ لَهُمْ ۖ

**«[Расүлем!] Синнән үзләренә нәрсәнең хәләл кылынганлыгын сорыйлар».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:4

Аллаһы безне белемгә омтылырга чакырып болай дип әйтә:

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ

**«Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләреннән сорагыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:43

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә белгәннәребез белән гамәл кылып, зиһеннәребезне ачык итсә иде, Раббыбызның әмерләренә буйсынып, хатакимчелекләрдән ерак булып яши алсак иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтач үзәк мәчетенең икенче имамы*

*11 нче август вәгазе,*
*мөхәррам аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ибраһим галәйһиссәлам – тәвәккәл итү үрнәге

Барча мактауларыбыз безне юктан бар иткән, безгә ризык биргән һәм безне туры юлга юнәлдергән Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде, сөйләгән вәгазьләребез, кылган гыйбадәтләребез файдалы булса иде.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِينَ قَالَ لَهُمُ النَّاسُ إِنَّ النَّاسَ قَدْ جَمَعُوا لَكُمْ فَاخْشَوْهُمْ فَزَادَهُمْ إِيمَانًا وَقَالُوا حَسْبُنَا اللَّهُ وَنِعْمَ الْوَكِيلُ

**«[Мөэминнәргә очраган] Инсаннар аларга: «Ул [дошманнарыгыз булган] кешеләр сезгә каршы [көч һәм гаскәр] туплады. Алардан куркыгыз!» – дигәч, бу [сүз] аларның иманнарын ныгыта гына төште һәм алар: «Аллаһы безгә җитә, Ул [бөтен эшләр тапшырыла торган] нинди яхшы Яклаучы!» – дип әйткән иделәр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:173

Белүебезчә, хаклыкны житкерүче Ибраһим галәйһиссәлам утка атарга дип бәйләнеп куелган халәттә әлеге сүзләрне әйтә, ягъни «Аллаһы безгә җитә, Ул [бөтен эшләр тапшырыла торган] нинди яхшы Яклаучы!» – ди.

Аллаһы безне һәрдаим яклыйдыр һәм Ул иң яхшы яклаучыдыр. Әгәр һәрберебез дә шушы сүзләрне күңелдән аңлап, калебебездән әйтсәк, тормышыбыз нигезеннән үзгәрер иде.

Бу дөньяда һәммәбезнең авырлыклары, кыенлыклары бар. Аларны хәл итүдә без Аллаһы Раббыбызга тәвәккәл кылсак, таулар кебек янган утлар да гөлбакчага әйләнер иде. Бу халәтне аңлар өчен, әйдәгез Ибраһим галәйһиссәлам вакыйгасына күз салыйк.

Белгәнебезчә, Ибраһим галәйһиссәламне утта яндырыр өчен, Нәмруд патша таулар кебек зурлыктагы ут якты һәм халкына утын тупларга әмер бирде. Араларында шундый хатыннар бар иде, авырта башласалар, хәтта: «Һичшиксез, сәламәтләнсәм, утын ташыйм», – дип нәзер әйтәләр иде. Халык бик озак вакыт, ашарына да учак якмыйча, утын ташыды.

Күзаллыйк әле, җәмәгать. Күпме кеше хаклыкны сөйләүчене яндырыр өчен, Аллаһының дустын утка атар өчен тырышты. Әмма хәдистә әйтелгәнчә: «...бөтен кешелек бергә кушылып, сиңа зарар кылырга теләсәләр дә, Аллаһы кушканнан артыгын эшли алмаслар...»[1]. Бу кешеләр барыбер пәйгамбәргә зарар сала алмадылар, бик тырышсалар да, Аллаһыга каршы бара алмадылар.

Нәмруд патша әмере белән Ибраһим галәйһиссәламне бәйләп, махсус җайланмага куйдылар һәм утка аттылар. Бер мизгел эчендә Җәбраил галәйһиссәлам килеп җитеп, Ибраһим галәйһиссәламгә: «Әй, Ибраһим, сиңа Аллаһының сәламе булсын. Әгәр теләсәң, ике тауны берләштереп, сиңа зыян салырга теләүче Нәмрудны һәм аның янында булганнарның һәммәсен юк итәм», – диде. Утка төшеп барган мизгелдә Ибраһим галәйһиссәлам: «Әй, Җәбраил, әйт әле миңа: Аллаһы мине күрәме?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әйе, күрә», – дип җавап бирде. Ибраһим галәйһиссәлам: «Аллаһы мине ишетәме?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әйе, ишетә», – диде. Ибраһим галәйһиссәлам: «Аллаһы минем хәлемне беләме?» – диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әйе, белә», – диде. Бу сүзләрдән соң, Аллаһының дусты: «Алай булса, сиңа, синең ярдәмеңә ихтыяҗым юктыр. Мин Раббыма тәвәккәл кылдым, чөнки Ул мине яклаячак. Аллаһы яклаучы буларак безгә җитә. Ул нинди яхшы Яклаучы!» – диде.

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан (*хәдис өлешчә китерелде – ред.*).

Утка атылу мизгелен карыйк, җәмәгать. Монда дүрт зат искә алына. Иң әүвәле – иң олуг яклаучы булган Раббыбыз, аннан соң утка атылучы Ибраһим галәйһиссәлам, моннан соң ярдәм итәргә теләүче Җәбраил галәйһиссәлам һәм зыян салырга теләүче Нәмруд патша. Әгәр авырлыкка очрасак, үзебезне утка очкандай күзаллыйк әле. Еш кына без, авырлыкны күреп, Раббыбызны онытабыз, авырлыкны яки аны китереп чыгаручыны искә алабыз, кешегә ярдәм артыннан барабыз, әмма, асылда, ярдәмне кем биргәнен, халәтне үзгәртүче Аллаһы булганын истән чыгарабыз. Юк, моны кешедән килгән ярдәмне кире борырга тиешбез, дип аңларга кирәкми. Киресенчә, бу ярдәмнең дә Аллаһыдан икәнен төшенергә тиешбез. Ләкин үз-үзебезгә шундый сорау бирик әле: авырлык килгәндә кемне искә алабыз? Бу вакыйга да нәкъ шул хактадыр. Утка атылу мизгелендә Ибраһим галәйһиссәлам утны искә алдымы? Әллә Нәмруд патшаны сүктеме? Яки: «Әй, Җәбраил, син кайда?» – дип, олуг фәрештәне ярдәмгә дәштеме? Юк! Ул бөтен халәте белән Аллаһыга бирелгән иде. Ә Ибраһим галәйһиссәлам урынында башка кеше булса, ул нишләр иде икән?

Нинди генә вакыйгалар булса да, нинди генә авырлыклар килсә дә, безнең күңелебездә, калебебездә, телебездә Аллаһы булырга тиештер. Һәм шул мизгелдә Аллаһы Раббыбыз янган утны да гөлбакча кылыр, кыздыра торган утны да салкын рәхәтлек итәр. Килгән авырлыгыбыз, бетмәс-төкәнмәс кыенлыкларыбыз бер мизгелдә сөенечкә әйләнер.

Бу вакыйгада тагын бер халәтне искә алу кирәктер. Учак ягылгач, кырмыска үзенең кечкенә авызына су алып, учакка ташыды. Башка җәнлекләр хәйран калып, кырмыскага шелтә белдерделәр: «Син нишлисең? Син суны сүндерә алмыйсың бит!» – диделәр. Әмма кырмыска үзенең җавабында: «Утны сүндерүче мин түгел, әмма Аллаһы миннән: «Ибраһимны утка ташлаганда син нишләдең?» – дип сорагач, мин: «Су ташыдым», – дип җавап бирермен», – дип әйтте.

Хөрмәтле җәмәгать, без дә кайвакыт, эшләгән эшебезнең мәгънәсе күренмәсә дә, нәтиҗәсе ерак булса да, кырмыска кебек булсак иде. Утны сүндерүче Аллаһы, әмма без учак янганда нишлибез? Нәкъ менә шунысын анлау мөһимдер. Нинди генә хәлдә булсаң да, үзеңнән торганны эшлә. Нәтиҗәсе – Аллаһыдандыр.

Тәвәккәллекне тасвирлый торган тагын бер вакыйганы карап китик: Һаҗәр анабыз Исмәгыйль галәйһиссәламне тудыргач, Ибраһим галәйһиссәламгә аларны хәзерге Мәккә жирлегенә алып барып, шунда калдырырга туры килде. Ул вакытта Исмәгыйль әле күкрәк сөте имүче бала иде. Ибраһим галәйһиссәлам аларны калдырып, аларга аркасы белән борылуга, Һаҗәр анабыз аның артыннан йөгерде һәм: «Әй, Ибраһим, ник син безне калдырасың? Безнең бит бер әйберебез дә юк», – диде. Ибраһим галәйһиссәлам җавап бирмәде, әмма Һаҗәр анабыз бик озак ялынды, соңыннан: «Сиңа моны эшләргә Аллаһы куштымы?» – дип сорады. Ул: «Әйе», – дип җавап бирде. Шулчак Һаҗәр анабыз: «Алайса Ул безне калдырмас!» – диде.

Аллаһы безне калдырмас! Уйлап карыйк әле, җәмәгать, чүл, корылык һәм берни дә: кеше дә, ашау да юк. Шундый хәлдә дә: «Алайса Аллаһы безне калдырмас», – дигән сүзләрне әйтер өчен нинди иман кирәк?! Без кайвакыт ризык тулы йортта, кеше тулы җирдә калганда да шикаять белдерәбез. Ә Һаҗәр анабыз кечкенә баласы белән чүлдә калганда да тәвәккәллек күрсәтте.

Бу урында якынча бер ун ел элек булган хәлне сөйләп үтәм. Яшь егет белән яшь кыз өйләнеп гаилә коралар, малайлары туа. Ире Аллаһы юлында хезмәт куя. Дөнья малы тормыш алып барырга җитә, шөкер кылып яшиләр. Төрле авырлыклар да килеп чыккалап тора, хатынының ипи алырга дип, калган бөтен тиенне жыйган чаклары булса да, зар белдермиләр. Көннәрдән бер көнне иренә хаҗга барырга юллама бирәләр. Тиз арада хәл итәргә кирәк була. Ир кеше сөенеп, очынып өенә кайта һәм хатынына: «Әнисе, мин хаҗга барам», – дип әйтә. Бу хәбәргә хатыны да куана. Ир кеше үз өстендә булган җаваплылыкны тоеп, борчылып куя, чөнки гаилә болай да ярым тук, ярым

киенгән хәлдә яши. Шул хәлдә аларны тагын бер айга калдырып китәргә тиеш икәнен аңлый ул. Хатыны иренең борчылганын күреп: «Ник уйга төштең?» – дип сорый. Ул: «Безнең матди хәлебез болай да авыр. Нишлим икән? Сезнең каршыда җаваплылыгым бар», – дип борчылуын белдерә ир кеше, – «Әле өстәвенә маллар да бар, үзеңә генә авыр булмасмы?» – ди. Аңа җавап итеп хатыны: «Ий, әтисе, Ибраһим галәйһиссәламнең Һаҗәр анабыз белән Исмәгыйльне чүлдә калдырганын оныттыңмы?! Аларның ризыклары, яннарында кешеләре юк иде. Ә без өй тулы ризык белән, кеше тулы җирдә калабыз. Аллаһы Раббыбыз чүлдә ризыксыз һәм сусыз калдырмаганны, монда да калдырмас әле», – дип әйтә.

Яңадан Һаҗәр анабыз вакыйгасына кайтыйк. Һаҗәр анабыз кечкенә Исмәгыйль янына кире килде, ә Ибраһим галәйһиссәлам тау кырыена барып җитеп Аллаһыга болай дип ялварды:

رَّبَّنَا إِنِّي أَسْكَنتُ مِن ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِندَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلَاةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِّنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُم مِّنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ

**«Ий, Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, [үзенә дә, янында яшәүчеләргә дә һөҗүм итү һәм мәсхәрәләү] харам кылынган йортың янында урнаштырдым. Ий, Раббыбыз! Намаз укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен [Мәккәгә урнаштырган гаиләмә һәм алардан таралачак яңа буыннарга] авыштыр һәм аларны [тирә-яктагы мәмләкәтләрдә өлгергән һәм ерак җирләрдән кайтарылган төрле-төрле] җимешләрдән ризыкландыр, – бәлки, алар [намазларын тиешенчә укып һәм бүтән гыйбадәтләрен җиренә җиткереп, бу нигъмәтләргә] шөкер итәрләр».**

«Ибраһим», 14:37

Һаҗәр анабыз Исмәгыйльне күкрәк сөте белән туендырды, ә үзе Ибраһим галәйһиссәлам калдырган суны эчте. Су беткәч, алар икесе дә бик каты сусадылар. Кечкенә Исмәгыйльнең сусызлыктан тилмергәнен күрә алмыйча, Һаҗәр анабыз Сафа тавына, Сафа тавыннан төшеп, Мәрва тавына йөгерде. Шулай итеп ул 7 тапкыр ике тау арасын йөгереп үтте. Мәрва тавында булганда ул үзенә: «Тыңла!» – дип әйтте һәм чылтырап аккан су тавышын ишетеп, Исмәгыйль янына йөгерде. Килеп җиткәч, чишмә суын күрде. Ул чишмә Зәм-зәм иде. Моннан соң Һаҗәр анабыз сусавы басылганчы су эчте һәм баласын ашатты.

Ибраһим галәйһиссәлам тәвәккәллекнең олы мисалыдыр. Аллаһы Раббыбыз безне тормыш юлы дәверендә төрле юллар, вакыйгалар аша юнәлтәдер. Җәмәгать, шуны белик: никадәр авыр булса да, таулар кебек янган утка керәсе булса да, сусыз чүлдә каласы булса да, ихластан тәвәккәллек кылсак, Аллаһы Үз рәхмәте белән азагын хәерле кылыр. Риза булып кабул иткән кешегә һәрбер урын яшәешкә яраклы булыр. Чүлдә дә чишмә чыгып, ул җирләр шәһәргә әйләнер. Риза булмаган кешегә чишмә тулы, ризык тулы җир дә чүлгә әйләнер. Бөтен мәсьәлә безнең әлеге халәтне кабул итүдәдер. Минем хакларым чикләнде дип үз тормышыбызны бозмыйк. Әгәр үзебез чикләмәсәк, хаклар чикләнми, җәмәгать. Бик күп еллар авыл жирендә торып олыгайган апаны йә абыйны шәһәргә алып китсәләр: «Ник мине дүрт дивар арасына бикләдегез?» – дип әйтәчәк. Шул ук вакытта шәһәрдә бер бүлмәле фатирда үскән, гомер иткән кешене 50 сутый җире булган авыл йортына алып кайтып куйсаң, ул да: «Ник минем хакларымны чиклисез?» – дияргә мөмкин.

Безнең кайда торуыбыз, нинди машинада йөрүебез, кем булып хезмәт кылуыбыз мөһим түгелдер. Безнең гамәлебез, булган әйбер белән ничек мөгамәлә кылуыбыз һәм никадәр авыр булса да, ни рәвешле Раббыбызга тәвәккәл кылуыбыз мөһим. Раббыбыз безне һәм Кыяматкәчә булган нәселебезне тиешле дәрәҗәдә тәвәккәл кылучылардан әйләсен. Әәмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Райнур хәзрәт Газизов,*

*Кукмара мөхтәсибәтенең «Нәсыйхәт» мәхәлләсе имамы*

*18 нче август вәгазе,*

*сафәр аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Аллаһының рәхмәтенә өметләник

Барча мактауларыбыз безне юктан бар иткән, безгә ризык биргән һәм безне туры юлга юнәлдергән Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде, сөйләгән вәгазьләребез, кылган гыйбадәтләребез файдалы булса иде.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الْإِنسَانَ خُلِقَ هَلُوعًا ﴿١٩﴾ إِذَا مَسَّهُ الشَّرُّ جَزُوعًا

**«Һичшиксез, кеше сабырсыз буларак яратылган. Аңа начарлык кагылган чакта [ниятләнгән бөтен эшләрне дә ташлар чиккә җитеп] кайгыручан».**

«Әл-Мәгариҗ / Баскычлар», 70:19-20

Бу аятьләрдән аңлашылганча, кеше бу дөньяга сабырсыз, хискә бирелүчән булып килә. Хисләр һәр кеше өчен гадәти, табигый нәрсә ул. Һәр кешенең төрле халәте: сөенечле вакытлары, өметсез чаклары була. Әлеге вәгазь борчылган вакытларда, күңел төшкәндә Раббыбыз Аллаһыга карата өметне югалтырга ярамаганлыгы хакында булыр.

Берәр авырлык килсә яки күп гөнаһ кыла башласа, кешенең күңеле төшә, чөнки бу аның вөҗданына каршы килә. Мондый хәлләр булганда Аллаһының рәхмәтенә өметне югалтмау мөһим. Моның хакта бик күп аятьләр һәм хәдисләр бар. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә:

وَرَحْمَتِي وَسِعَتْ كُلَّ شَيْءٍ

**«... рәхмәтем исә һәрнәрсәне каплап алган...»** – дип әйтә.

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:156

Ягъни бу аятьтән аңлашылганча, Раббыбызның рәхмәте бик киң һәм барыбызны да үз эченә ала. Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен риваять итә: «Бар нәрсәгә кодрәтле һәм бөек Аллаһы: «Берәү (бер) изге гамәл кылса, аны ун әҗер (көтә) яки Мин аңа тагын өстәрмен. Начар гамәлне кылучыга килгәндә, аның җәзасы шул начарлыгы кадәр булыр яки Мин (аны) гафу итәрмен. Берәү Миңа бер карышка якынайса, Мин аңа бер терсәккә якынаермын. Миңа бер терсәккә якынаючыга Мин бер сажинга[1] якынаермын. Берәү Миңа таба бер адым атласа, Мин аңа йөгереп килермен. Берәү Миңа бөтен җирне (томаларлык) гөнаһлар кылып килсә, ләкин (шул ук вакытта) Миңа гыйбадәт кылуда тиңдәш кылмаса, Мин (бу бөтен гөнаһларны каплармын) ярлыкау белән аны каршы алырмын», – дип әйтә»[2]. Бу хәдиснең мәгънәсе: «Миңа итагать итү ярдәмендә Миңа якынаючыга Үземнең рәхмәтемне күрсәтеп якынаермын. Әгәр ул артыгын кылса, Мин (аның өчен) артыграк кылырмын; Миңа бер адым атлаучыга һәм Миңа итагать итәргә ашыгучыга Мин тагын да якынрак булырмын». Аллаһы бу хакта яхшырак белә.

Болай дип риваять ителә: Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Аллаһы мәрхәмәтне 100 өлешкә бүлде, 99ын Үзендә калдырды, ә бер өлешен Җиргә иңдерде, шул сәбәптән, бөтен мәхлукълар бер-берсенә карата мәрхәмәтлелек күрсәтә. Балаларына басудан куркып, үзләренең тоякларын алучы атланып йөри торган хайваннар да мәрхәмәтлелек күрсәтәләр», – дип әйткәнен ишеттем».

Болай дип риваять ителә: Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Кыямәт

1 Сажин – элеккеге үлчәү берәмлеге.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

көнендә мөэмин Раббысына якынайтылыр һәм Ул аны Үз яклавы астына алыр. Ул аны үз гөнаһларын танырга мәҗбүр итәр һәм: «Фәлән, гөнаһ кылуыңны танийсыңмы?» – дип сорар. Ул: «Йә, Раббым, таныйм!» – дип җавап бирер. Шунда ул: «Дөреслектә, Мин синең гөнаһларыңны дөньяда вакытта капладым. Мин аларны бүген ярлыкыйм», – дип әйтер. Шуннан соң аңа изге гамәлләре язылган китапны бирерләр»[1].

Кеше, берәр авырлык килсә, өметен югалта. Бу да дөрес эш түгел. Авырлык, сынау килгән очракта безгә күркәм әхлак күрсәтеп, сабыр ияләреннән булырга, Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәскә кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ۚ

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلَاةِ ۚ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ

**«Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Ягъни ошбу аятьләрдән аңлашылганча, безнең өметне югалтырга хакыбыз юк, сабыр ияләреннән булып, Раббыбызның рәхмәтенә омтылучылардан булырга тиешбез.

Иң сабыр кешеләр – ул пәйгамбәрләр, ә пәйгамбәрләрнең иң сабыры – Әюб галәйһиссәлам. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә аңа күп сынаулар бирде.

1 Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Алдан ул бай, сәламәт иде, соңыннан авыру, фәкыйрь булды. Башта аның зур гаиләсе бар иде, соңыннан бөтен балалары үлеп бетте. Әмма ул ныклык күрсәтеп, сабыр ияләреннән булды, ризасызлыгын белдермәде, күп еллар буе тәкъдиргә риза булып яшәде. Нәтиҗәдә, Аллаһы Тәгалә аннан разый булды һәм аңа Үзенең рәхмәтен иңдерде, байлыгын моңа кадәр булганнан да күбрәк бирде, саулыгын кайтарды, балалары башта булганнан да күбрәк булды. Әюб галәйһиссәлам сабырларның солтаны һәм безнең өчен үрнәк булып тора.

Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең һәрвакыт күреп, ишетеп торуын онытмаска тиеш. Бу дөньяда кеше канатлы кош сыман, бер канаты өмет булса, икенче канаты Аллаһы Тәгаләдән курку булырга тиеш. Кеше шул өмет белән курку арасында яшәгәндә генә тынычлыкка ия була.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Раббыбыз Аллаһы барыбызга да ихтыяр көчен, сабырлыклар биреп, Үзенең рәхмәтендә, мәгъфирәтендә һәм ризалыгында булуны насыйп итсә иде. Бу дөньяда да, Ахирәттә дә бәхет ияләреннән булып, Кыямәт көнендә ким-хур булучылардан кылмаса иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габдулла хәзрәт Гыйззәтуллин,*
*Бөрбаш балалар пансионаты остазы,*
*Бөрбаш авылы мәчетенең икенче имамы*

*25 нче август вәгазе,*

*сафәр аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Хәләл хезмәт хакының кыйммәте

Барча мактауларыбыз безне юктан бар иткән, безгә ризык биргән һәм безне туры юлга юнәлдергән Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде, сөйләгән вәгазьләребез, кылган гыйбадәтләребез файдалы булса иде.

Хөрмәтле мөселманнар! Ислам динендә мал-мөлкәт мөнәсәбәтләрен өйрәнүнең мөһимлеге һәм хәләл хезмәт хакының кыйммәте зур. Ислам дине безгә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә тарафыннан бирелгән, мөселман кешесе тормышының бар якларын үзенә алган илаһи күрсәтмә ул.

Бу – гыйбадәт кылу бүлекләре: тәһарәт, намаз, ураза һәм хаҗ да, бу – гаилә мөнәсәбәтләре: никах, ир белән хатынның бурычлары һәм хокуклары, балалар тәрбияләү һәм башкалар да, бу – мал-мөлкәт мөнәсәбәтләре, мөгамәләт: сәүдә кагыйдәләре һәм аренда, рибаның, зур билгесезлек белән төзелгән килешүнең тыелуы да. Шуның белән бергә шәригатьнең барлык бүлекләре дә үзара бәйләнгән: мирас бүлү – ул бер үк вакытта милеккә дә, гаилә мөнәсәбәтләренә дә кагыла.

Кызганычка, бүгенге көндә күп кенә мөселманнар динне йолаларга: исем кушу, никах, җеназа үткәрүгә һ.б. гына кайтарып калдыра. Һичшиксез, йолалар да мөһим, әмма Ислам дине алар белән генә чикләнми.

Намаз укучы, Рамазан аенда ураза тотучы, хаҗга, гомрәгә баручы күп кенә мөселманнар еш кына Исламның гыйбадәт кылуга кагылышлы темаларын өйрәнү белән генә чикләнә. Әмма Ислам – аерым бер кешенең һәм, гомумән, җәмгыять тормышының бар якларын үз эченә ала торган кануннар системасы ул.

Хәләл һәм харамга кагылышлы булган сорауларны өйрәнү мөселман кешесенең иң мөһим бурычларының берсе булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, хәләл дә билгеле, харам да билгеле. Алар арасында күп кеше белми торган шикле нәрсәләр бар. Шикледән сакланучы кеше, динен һәм намусын саклар өчен, аннан котыла. Ә шикле булган нәрсәләрне кылучы харамны кылуга киләчәк, чөнки ул тыюлык янында көтү көтеп, көтүе менә-менә тыюлыкка керәчәк көтүчегә тиң. Хакыйкатьтә, һәр патшаның шундый тыюлыгы бар. Ә Аллаһының тыюлыгы – ул Аның кешеләргә харам кылган нәрсәләре»[1].

Без хәләл яки харам дип, ит яки казылык кына санала ала дип уйларга җыяләшкән. Ләкин без сату-алу мәсьәләсендә харам килешүләр дә була алуын һәм аларның Кыямәт көнендә начар гамәлләр үлчәвенә гөнаһ булып салынуын беләбезме икән?

Акча һәм мал-мөлкәт – Аллаһы Тәгалә кешеләргә биргән олуг нигъмәт ул. Раббыбыз болай дип әйтә:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا

**«Ул [Аллаһы] Җирдә булганнарның бөтенесен сезнең [мәнфәгатегез] өчен яратты».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:29

Ягъни, хөрмәтле дин кардәшләрем, Җир йөзендә булган барлык нигъмәтләр, шул исәптән, милек тә безнең барыбыз өчен дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгән. Һәм бу нигъмәтләр кешегә билгеле бер вакытка кулланып тору өчен генә бирелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хакыйкатьтә, Җир йөзенең нигъмәтләре татлы һәм саф, хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә сезне Җир йөзендә (Үзенең) хәлифәләре итте һәм Ул сезнең нәрсә кылганыгызга, ягъни сезгә

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

кулланылышка бирелгән нигъмәтләр, мал-мөлкәт белән ни рәвешле эш итүегезгә карый»[1].

Һәм берәү хәләл булган нигъмәтләрне кулланса, хезмәт хакын хәләл юл белән тапса, ул кеше үз вазифасын үти, Аллаһы Тәгалә ул кешедән риза була. Мал-мөлкәт аның өчен мәңгелек нигъмәтләргә ирешү чарасы һәм җәннәткә илтә торган юлда әзерлек булып тора.

Ә берәү бары тик дөнья эшләренә генә бирелгән булса, байлык һәм танылуны үзенең төп максаты итсә, хәләл һәм харам мәсьәләләренә тиешле дәрәҗәдә карамаса, ул кеше Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең ачуы астында йөрер. Барлык яхшылыкларны ул бу дөньяда ук алып бетерсә дә, мәңгелек тормышта аны, Аллаһы Тәгалә гафу кылмаса, җәзадан башка нәрсә көтмәс.

Бу хәдиснең башка вариантында болай дип әйтелгән: «Хакыйкатьтә, Җир йөзенең нигъмәтләре татлы һәм саф. Һәм әгәр берәү үзенең хакы булган нәрсәне алып, аны дөрес итеп кулланса, ул кеше дөрес гамәл кылган булыр. Ә берәү үзенең хакы булмаган нәрсәне алса, ул ашап та тукланмаган кеше кебек булыр»[2].

Һәрбер мөэмин, яхшылык эшләр һәм начарлыктан качар өчен, нәрсәнең хәерле һәм нәрсәнең хәерле булмавын өйрәнергә тиеш. Әйтелгәнчә, начарлыкны белмәүче, һичшиксез, аңа тап булачак. Һәм хәләл белән харамның кайдалыгын белмәүче иртәме-соңмы харам гамәл кылачак. Шикле нәрсәләрдән сакланмаучы да иртәме-соңмы шулай ук харамга төшәчәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзенең хакы булган нәрсәне алучыга Аллаһы Тәгалә мал-мөлкәтенең бәрәкәтен бирер», – дигән мәгънәдәге сүзләр әйткән. Сүз бәрәкәт вәгъдә ителгән хәләл кәсеп хакында бара. Мондый мал-мөлкәт үсәчәк, артачак һәм бары тик хәерле җимешләрен генә бирәчәк.

---

[1] Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Шунда ук.

Имам Әл-Бохари «Әдәб әл-мофрад» китабында мондый хәдисне җиткергән: «Хәерле, хәләл мал-мөлкәт – изге кеше өчен игелек».

Һәм, киресенчә, берәү харам юллар белән акча эшләсә, шул кеше кәсебенең бәрәкәтен югалтыр.

Иман һәм мөгамәләт арасында турыдан-туры элемтә бар. Иман – ул Ислам динендә җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр төзелә торган нигез дә, һәм кешегә башка кешеләр белән мал-мөлкәт мөнәсәбәтләрендә шәригать рөхсәт иткән чикләрдән чыгарга бирми торган тыеп торучы башлангыч та.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә иман белән мал-мөлкәт мөнәсәбәтләрен бәйләп, болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَوْفُوا بِالْعُقُودِ ۚ

> **«Ий иман китерүчеләр! [Сезгә Аллаһы тарафыннан йөкләнгән хәләл һәм харам хөкемнәр белән бәйле, янә үз арагызда тугры сүз бирелгән әманәтләр һәм мөгамәләләр белән бәйле бөтен] килешүләрне [җиренә җиткереп] үтәгез».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:1

Шәригать кагыйдәләрен үтәп башкарылган сәүдә эше Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу һәм бәрәкәт алу чарасы була ала.

Мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләгә намазда гына түгел, ә базарда, эш урынында, сату-алу килешүләре төзегәндә һәм башка вакытларда Аның әмерләрен үтәп тә, гыйбадәт кыла ала. Мондый эшләрдә аның Җир йөзендәге һәм мәңгелек тормышлары бер-берсенә орына.

Имам Мөхәммәд бине Хәсән Әш-Шәйбанидән: «Нигә син тәсаввуф хакында китап язмыйсың? Фикһ хакында китап яздың бит», – дип сораганнар. Имам: «Мин сезгә сәүдә хакында китап яздым», – дип җавап биргән.

Бу сүзләре белән ул хәләл һәм харам кагыйдәләре китерелгән сәүдә хакындагы китап язуы хакында әйтергә теләгән. Кешеләр белән мөгамәләдә кешенең иманы ни дәрәҗәдә булуы билгеләнә һәм акча мәсьәләләрендә бу

барыннан да бигрәк чагылыш таба – аның дөнья рәхәтеннән ваз кичүе яки саранлыгы ачыла.

Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Сезне кешенең уразалары һәм намазлары алдамасын, аның дөрес сөйләвенә, аңа ышанып тапшырылганны кайтарып бирүенә һәм авыр хәлгә дучар булгач, тәкъвалык күрсәтүенә карагыз». Ягъни аның харамнан саклануы мөһим.

Тәсаввуф иске кием киеп йөрүдә, искергән ризык ашауда түгел. Суфыйчылык – хәләлне эзләгәндә харамнан ерагаюда. Моның хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үзеңне харамнан сакла – Аллаһыга иң күп гыйбадәт кылучы булырсың. Аллаһы сиңа биргәнгә риза бул – иң бай кеше булырсың»[1].

Шулай булгач, сәүдә һәм мал-мөлкәт мөнәсәбәтләренә кагылган шәригать хөкемнәрен өйрәник һәм килешүләребездә хәләллек кагыйдәләрен үтик.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Дәгъват бүлеге*

1 Имам Әт-Тирмизинең хәдисләр җыентыгыннан.

*1 нче сентябрь вәгазе,*

*сафәр аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гыйлем алу фазыйләте

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гыйлем бирүче галим бул, йә гыйлем өйрәнүче бул, йә аларның сүзенә колак салучы бул, гыйлемгә һәм гыйлем әһеленә мәхәббәтле бул, тик бишенчесе булма. Һәлак булырсың», – дип әйткән.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Гыйлем сүзе Коръәни Кәримдә 70 тән артык урында кабатланып килә. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

> **«Аллаһы да арагыздан иман китергәннәрне һәм гыйлем бирелгән кешеләрне дәрәҗә ягыннан күтәрер. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар».**

«Әл-Мүҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Чыннан да, бүгенге көндә гыйлем зур байлык булып тора. Һәм, Аллаһыга шөкер, аны алу юллары да җиңеләйде. Үзебезнең җирлегебездә мәктәпләр, мәдрәсәләр, техникумнар, югары уку йортлары бар көчләренә эшләп килә. Нинди генә өлкә буенча укырга теләсәң дә, еракка китәргә кирәк түгел. Шулай да, гыйлем алу тәртибен, рәвешен бик үк дөрес аңламаган кешеләрне дә очратырга мөмкин. Кайбер ата-аналар балаларын мәдрәсәгә генә бирүне кулай күрә. Алар өчен җөмһүриятебездәге дөньяви уку йортларына укырга керү бер хата булып тора. Мәдрәсәләрне тәмамлаган кайбер шәкертләр белән күрешеп сөйләшергә туры килә, араларында башка беркая да укырга кермәячәген әйткәннәре дә бар. Ягъни дөньяви гыйлемнең Ахирәт өчен файдасы юк, имеш.

Аллаһы Тәгалә безне бик катлаулы кануннарга корылган Җир шарына урнаштырды. Бу дөньядагы барлык нәрсәләрнең дә бер тәртибе бар. Һәм шуңа күрә: «Мин бары тик мәдрәсәдә генә укыячакмын, дөньяви уку йортына бармаячакмын», – диючеләр дә, «Баламны мәдрәсәгә кертеп тормыйм, искелектән ерак булсын», – дип әйтүчеләр дә бик нык ялгыша. Әйткәнебезчә, Аллаһы Тәгалә безне кануннар белән тулы булган дөньяга урнаштырды һәм ул кануннарны өйрәнү өчен ике дөнья гыйлемен дә белү мөһим.

Аллаһыга шөкер, без күрә, ишетә, сөйләшә, йөри алабыз. Әмма беркайчан да боларны ничек эшләвебез хакында фикер йөртмибез. Ә көннәрдән бер көнне кеше күз күремен югалтса, аңа ни эшләргә соң? Әгәр кеше дөньяви гыйлемнәрне инкяр итә һәм бу гыйлемнәргә ия булырга омтылмый икән, күз табибы дигән белгечләребезне кем әзерләр?! Алардан аласы ярдәмне каян эзләрбез?!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә кошларның һавада ни рәвешле очканнарына кадәр аңлаткан. Мәдрәсәдә генә гыйлем алу белән чикләнеп, дөньяви гыйлемнәргә омтылмасак, кешеләргә, җәмгыятькә ярдәм итүне максат итеп куймасак, бу дөрес булырмы? Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә үткен фәһемлек, зиһен, хикмәт бирсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ

**«Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән [хакны] белмәгән [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] кешеләр тиң була аламы?»**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Коръән безне гыйлем алуга чакыра. Безнең бу дөньябыздагы бәрәкәтебез дөньяви гыйлем белән берлектә дини гыйлемне алудан тора. Мөэмин-мөселман кешесе иртәгә бу дөньядан китәм дигәндәй гыйбадәт кыла һәм мәңге яшим дигән сыман дөнья көтә. Бу ике гамәл кешегә ике дөнья бәхетенә ирешергә ярдәм итә.

Дөньяви гыйлем белән берлектә дини гыйлем туплауның әһәмияте дә зур. Бәлки кайбер кеше: «Ни өчен дини гыйлем дә кирәк соң?» – дип сорар. Җәмәгать, күбебез Аллаһы Тәгаләнең кешеләрне дә, җеннәрне дә бары тик гыйбадәт кылсыннар өчен генә яратканын белә. Бу хакта Коръәндә дә әйтелгән:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Шуны белик: гыйбадәт кылу нинди дә булса гамәлләрне күз алдында тота. Намаз укыйбыз икән, анда укыла торган сүрәләрне, догаларны белергә, намазга соңга калып килгәнбез икән, ничек имамга кушылырга икәнен белергә тиешбез. Кеше эшмәкәр булса, акчасыннан зәкят бирү мәсьәләсе туачак. Зәкятне кайчан, нинди күләмнән, күпме бирәсе; яңгыр белән үстерелгән яшелчәдән күпме гошер чыгарасы – боларның барысына да Коръәннән

һәм Сөннәттән җавап табарга туры киләчәк. Димәк, дини гыйлемне дә алырга кирәк.

Шуңа күрә, нинди генә гамәлгә тотынсак та, иң беренче чиратта, үзебездә тиешле гыйлем тупланган булырга тиеш. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, игътибар итегез: Аллаһы Раббыбыз Коръәннең иң беренче аяте белән безне белем алырга чакыра:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

**«Яратучы Раббың исеме белән [башлап, Коръәнне] укы!»**

«Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:1

Шуңа да безгә гыйлемнең бөтен кешелек өчен әһәмиятле булуын аңлау кирәк. Кешелек тормышын чорнап алган нинди генә өлкәне алсак та, барысына да: трактор-машина йөртү өчен дә, тегү-чигү өчен дә, табиб, укытучы булыр өчен дә гыйлем кирәк. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә:

وَرَحْمَتِي وَسِعَتْ كُلَّ شَيْءٍ ۚ

**«... рәхмәтем исә һәрнәрсәне каплап алган»,** – дип әйткән.

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:156

Ислам динендә гыйлем алу һәр мөселманга фарыз итеп куелган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гыйлем алу һәрбер мөселман кешесе өчен фарыз»[1], – дип әйткән. Шуңа күрә һәрбер мөселман кешесе үзенә кирәкле булган гыйлемнәрнең иң аз өлешен булса да белергә тиеш. Бу аның бурычы булып тора. Әлхәмдүлилләһ, бүгенге көндә барыбызның да мондый мөмкинлеге бар. Бездән ышанычлы чыганакларга таянып, билгеле бер тәртипкә муафыйк рәвештә гыйлем алу гына таләп ителә, чөнки Аллаһы Тәгалә каршында булган фарызларыбызны тиешенчә үти алыр өчен, гыйлемгә ия булырга тиешбез. Мәсәлән, намаз уку, тәһарәт алу, ураза тоту

[1] Имам Әт-Табәранинең хәдисләр җыентыгыннан.

хакында белергә тиешле булган мөһим гыйлемнәрне алмасак, бу гамәлләрне башкаруда хата-кимчелек җибәрергә мөмкинбез. Шуңа да остазларыбыз, имамнарыбыз, мәчет-мәдрәсәләребез, ышанычлы, дөрес булган чыганакларга таянып әзерләнгән китапларыбыз безнең төп ярдәмчеләребез булса иде.

Динебез белем-мәгърифәткә бик зур игътибар бирә. Без дини һәм фәнни гыйлем дип тә әйтергә яратабыз.Фәнни гыйлемгә «дөньяви» дигән ярлык тагылса да, Ислам динендә дин һәм фән – игезәкләр кебек, бер-берсенә бәйле. Әмма без аны сизмәскә дә мөмкин. Дини гыйлем дә, дөньяви гыйлем дә янәшә атлап баручы ике дус кебек. Бу юлда алар бер-берсенә ярдәм итешеп, бер-берсен тулыландырып хәрәкәт итә. Дини гыйлем фарызларыбызны тиешенчә үтәүдә ярдәм итсә, дөньяви гыйлем, ягъни фән гыйлеме тормыш кануннарын өйрәнеп, шул кануннар белән яшәешебезнең бәйләнешен аңларга ярдәм итә.

Мәсәлән, Коръәни Кәрим баланың ана карынында барлыкка килүен, аның этапларын, таулар, болытларны, күк җисемнәренең хәрәкәтен, диңгез-океан серләрен ачып бирә. Санап киткән әйберләрнең барысы да төрле өлкәләргә карый. Коръәндә җиһан хакында да язылган:

وَالسَّمَاءَ بَنَيْنَاهَا بِأَيْدٍ وَإِنَّا لَمُوسِعُونَ

**«Күкне Без зур бер куәт белән кордык [чөнки бу эш бик зур көч таләп итә]. Һичшиксез, Без зур көчкә иябез».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:47

Бу күренешләрнең барысын да дәүләт университетларында эшләүче галимнәр өйрәнә. Ә Аллаһы Тәгалә бик күптән халыкка болар хакында җиткергән инде. Әгәр Аллаһы Тәгалә мөселманнарга дини гыйлемнән тыш, ошбу дөньяга караган гыйлем дә биргән икән, димәк, без аны кабул итәргә, өйрәнергә тиешбез.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, шуны әйтик: гыйлем кешене ике дөнья бәхетенә ирештерә, гыйлемле кеше бу дөньяда җәмгыятькә, кешелеккә

файдалы булып гомер итә, Кыяматтә, иншәАллаһ җәннәт дәрәҗәләренә ирешә. Шуңа да мөмкинлеге булган кеше гыйлем алудан курыкмаска, һәрвакытта да гыйлемгә вакыт табарга тырышырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә тәүфыйк, һидаять биреп, безләрдән разый булып, безләрне югары дәрәҗәләргә күтәрсә иде. Алган гыйлемнәребез белән гамәл кылып, җәмгыятебез, кешелек өчен файдалы шәхесләр булып яши алсак иде. Әәмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*8 нче сентябрь вәгазе,*

*сафәр аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гошер садакасы бирү

Көнне төн белән алыштыручы һәм елларны вә айларны яңартучы, Ислам дине белән туры булган һидаятькә күндерүче вә чиксез олуг нигъмәтләрен бирүче Аллаһы Раббыбызга хәмед-сәналәребез һәм мактау-олуглауларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның әһле бәйтенә һәм сәхабәләренә хәер-дога, сәламнәребез, туктаусыз салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Мөхтәрәм газиз мөселман кардәшләрем! Бүгенге җомга шәриф көнебездә сөйләнәсе вәгазебезнең эчтәлеге гошер садакасы хакында булачак.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

وَهُوَ الَّذِي أَنشَأَ جَنَّاتٍ مَّعْرُوشَاتٍ وَغَيْرَ مَعْرُوشَاتٍ وَالنَّخْلَ وَالزَّرْعَ مُخْتَلِفًا أُكُلُهُ وَالزَّيْتُونَ وَالرُّمَّانَ مُتَشَابِهًا وَغَيْرَ مُتَشَابِهٍ ۚ كُلُوا مِن ثَمَرِهِ إِذَا أَثْمَرَ وَآتُوا حَقَّهُ يَوْمَ حَصَادِهِ ۖ وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ

**«Ул – [төс, тәм, зурлык һәм ис ягыннан] җимешләре төрле булган терәкле һәм терәксез [йөзем куаклары үскән] бакчаларны да, хөрмәләрне, игеннәрне дә, [төсе һәм тәме белән] бер-берләренә охшаш һәм охшамаган итеп зәйтүн һәм анарларны яратучы. Уңыш биргән вакытларында, сез [боларның бөтенесенең] җимешләрен ашагыз, урып [җыеп] алган көнне исә хакын [гошер һәм зәкятен] бирегез, ләкин [бала-чага һәм гаилә әгъзаларын мохтаҗ калдырырлык дәрәҗәдә күп биреп] чиктән ашмагыз. Һичшиксез, Ул исраф итүчеләрне сөйми»**, – дип әйтә.

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:141

Һәм икенче аяте-кәримәләрдә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَنفِقُوا مِن طَيِّبَاتِ مَا كَسَبْتُمْ وَمِمَّا أَخْرَجْنَا لَكُم مِّنَ الْأَرْضِ ۖ

**«Ий иман китерүчеләр! [Кәсеп итеп] Тапканнарыгызның иң яхшыларын [хәләлләрен] һәм Безнең сезнең өчен җирдән чыгарган нәрсәләребездән [садака итеп] сарыф итегез»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:267

وَمَا أَنفَقْتُم مِّن نَّفَقَةٍ أَوْ نَذَرْتُم مِّن نَّذْرٍ فَإِنَّ اللَّهَ يَعْلَمُهُ ۗ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنصَارٍ

**«Хәер-садака итеп нәрсә сарыф итсәгез яки нәзер итеп өстегезгә нәрсә йөкләсәгез дә, һичшиксез, Аллаһы моны белә [һәм шуңа карата әҗерен дә бирә]. Залимнәргә [Аллаһы Тәгаләнең газабыннан коткара алырлык] ярдәмчеләр юк».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:270

Садакалар арасында барыбызга да билгеле булган гошер садакасы бар. Бу төр садака иң хәерле һәм бәрәкәтле садакалар төреннән санала. Гошер садакасы – җирдән яңгыр суы белән үстерелгән, көндәлек тормышыбызда ризык итеп куллана торган үсемлек, азык нигъмәтләреннән уннан бер өлешне бирү ул. Әгәр кеше җирдә үскән яшелчәләрне су сибеп үстергән булса, ул вакытта егермедән бер өлешен бирә торган була.

Гошер садакаларын безнең җирлектә, гадәттә, мохтаҗ кешеләргә, мәчет-мәдрәсәләргә тапшыралар. Шулай ук бу садаканы фәкыйрь, мескен, ятим кешеләргә, гыйлем алу юлындагы шәкертләргә, ялгыз яшәүче әбибабайларга бирергә мөмкин.

Пәйгамбәребез сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм мөбарәк хәдисендә болай дип әйтә: «Садака малны киметмәс. Һәм кешенең гафу итүе сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аңа бөеклектән башка нәрсә бирмәс. Үзен Аллаһы Тәгалә каршында түбәнчелекле тоткан кешене Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, бөек фазыйләткә күтәрер».

Икенче хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем дә кем, садаканың кыйммәтен белеп, хәләл кәсептән садака бирсә, Аллаһы Тәгалә кабул иткәндә иң яхшы булганын кабул итәчәк. Бәс Аллаһы Тәгалә бәндәнең биргән садакасын уң тарафыннан кабул итәчәк. Моннан соң сезләрдән берәүләрегез яшь тайны тәрбияләп, ат дәрәҗәсенә җиткергән кебек, хәтта бер хөрмәдән тау зурлыгындагы әҗер-савапларның күплегенә ирешкәнгә кадәр, Аллаһы Тәгалә садака иясенең садакасын ишәйтер».

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا أَنفَقْتُم مِّن شَيْءٍ فَهُوَ يُخْلِفُهُ ۖ وَهُوَ خَيْرُ الرَّازِقِينَ

**«Әмма [изге юлда] нәрсә дә булса сарыф итсәгез, Ул аның урынына [кат-кат арттырып] алмашын бирер. Ул – [бөтен ризыкларны бар иткән Аллаһы булганлыктан] ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе».**

«Сәбә», 34:39

Әлбәттә, дөньяда иманлы бәндәнең биргән изгелек хакларын Аллаһы Тәгалә буш калдырмас, мул ризык, сәламәтлек киң дәүләт юлын ачып, тапкан малларының бәрәкәтләрен бирәчәк һәм бу кеше Ахирәттә Аллаһы ризалыгына ирешеп, олы әҗер-савапларга ия булачак.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا تُنفِقُوا مِنْ خَيْرٍ فَلِأَنفُسِكُمْ ۚ وَمَا تُنفِقُونَ إِلَّا ابْتِغَاءَ وَجْهِ اللَّهِ ۚ وَمَا تُنفِقُوا مِنْ خَيْرٍ يُوَفَّ إِلَيْكُمْ وَأَنتُمْ لَا تُظْلَمُونَ

**«Хәердән нәрсә бирсәгез, [моның әҗере] үзегез өчен. Сез Аллаһының ризалыгын өмет итүдән тыш, башка бернәрсә өчен сарыф итмисез. Хәердән нәрсә сарыф итсәгез, [савабы] сезгә тулысынча кайтарылачак, һәм сезгә [әҗер-савапларыгыз киметелеп] золым ителмәячәк».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:272

Киләсе аятьләрдә болай дип әйтелә:

وَمِنْهُم مَّنْ عَاهَدَ اللَّهَ لَئِنْ آتَانَا مِن فَضْلِهِ لَنَصَّدَّقَنَّ وَلَنَكُونَنَّ مِنَ الصَّالِحِينَ ﴿٧٥﴾ فَلَمَّا آتَاهُم مِّن فَضْلِهِ بَخِلُوا بِهِ وَتَوَلَّوا وَّهُم مُّعْرِضُونَ

**«Алар арасында: «Әгәр Аллаһы Үзенең фазылыннан безгә [күп мал] бирсә, әлбәттә, садака [вә зәкят] бирербез һәм, һичшиксез, [туганлык җепләрен саклап, хаҗга барып һәм Аллаһы юлында ярдәм итеп] игелек ияләреннән булачакбыз», – дип Аллаһыга вәгъдә бирүчеләр бар. Ләкин Ул аларга Үз фазылыннан [байлык] биргәч, алар [сүзләрендә тормыйча] саранландылар [һәм Аллаһының хакын бирмәделәр], [Аллаһының әмерен] кире каккан хәлдә йөз чөерделәр».**

«Әт-Тәүбә», 9:75-76

Ягъни Аллаһы Тәгалә аңа байлык биргәндә алар саранлык кылдылар һәм башларын борып, Аллаһының әмерен кире кактылар.

Хөрмәтле кардәшләрем, һәрберләребезгә дә Аллаһының сүзләрен, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөбарәк хәдис-шәрифләрен ишетеп, шулар белән гамәл кылуларыбыз, Аллаһы Раббыбызның ризалыгын табып, ике дөнья бәхетенә ирешүләребез насыйп булса иде.

Хәләл кәсеп һәм хәләл ризыклар белән ризыкланып, Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылып яшәүләребез насыйп булса иде. Аллаһы Сөбеханаһу вә Тәгалә балаларыбызга, оныкларыбызга киләчәк буын нәселләребезгә иманда һәм

Исламда тормыш итүләребезне, динебезне саклап, аны дәвам итүче хәерле нәселләр калдыруыбызны һәм безләргә Кыяматкә кадәр аларның хәер-догаларына ирешүләребезне насыйп әйләсә иде. Әәмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллин,*
*Яшел Үзән районы мөхтәсибе*

*15 нче сентябрь вәгазе,*
*сафәр аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ислам дине тынычлыкка өнди

Барлык галәмнәрне юктан бар кылып, ризыкландырып, нигъмәтләндереп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу Хак Тәгаләгә мактау олуглауларыбыз, хәмде-сәналәребез булсын. Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, безне ут газабыннан котылу, җәннәткә илтү юлларын өйрәтеп калдырган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихлас күңел түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен.

Соңгы елларда адәм балаларына диндә ирек куелды. Күп кенә кешеләр ничә еллар динсезлектә яшәгәннән соң, яңадан үз диннәрен тотып яшәү өчен киртә булмавын аңладылар. Туксанынчы елларда бабайларыбыз әтиәниләреннән ишеткән, отып калган гамәл-гыйбадәтләрне торгызу өстендә зур көч куеп эш башладылар. Дин халык күңелендә үлмәде, һәркем Раббысына ышанды, Аңа күңеленнән ихлас мөрәҗәгать итте. Ислам янәдән кешеләр күңелендә яшәрде, яши башлады.

Ислам дине – тынычлык дине. Ислам сүзенең тамырында булган «сәлам» сүзе тынычлык, иминлек дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бөтен мөселманнарга дөньяга тынычлык, хозур һәм кардәшлек китерүләрен әмер итә. Мөселманнарга башка дин әһелләренә карата да гүзәл әхлак күрсәтү, аларның да яхшылыгы өчен тырышу җаваплылыгы йөкләнгән. Әйе, мөселманнарны фетнә чыгаручылар, кан коючылар итеп күрсәтергә тырышучылар бүген шактый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне бу хакта хәдис-шәрифләрендә кисәтеп куя. Ничек кенә булса да, без – мөселманнар, динебездә нык торырга тиешбез. Татар халкының «Таш атканга аш ат» мәкале дә юктан гына чыкмаган. Начарлыкка начарлык белән җавап бирү – явызлыкка юл кую, аны арттыру дигән сүз. Ә инде сиңа карата яманлык кылучыга изгелек белән җавап бирү, кимендә тыелып калу – үзеңә

савап алу гына түгел, ә бәлки, Аллаһы Тәгалә кушуы белән, теге кешенең күңелен йомшартуга, кылган начар гамәлләренә тәүбә итүгә, киләчәктә бары яхшылыклар, изгелекләр башкаруга сәбәпче дә булырга мөмкин. Мөселман кешесе башкаларга сабырлыкның, гаделлекнең, ихласлыкның, тынычлыкның үрнәге булырга тиеш. Бу безнең изге максатыбыз булып тора. Аллаһы Раббыбыз бу уңайдан Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ

> **«Кешеләр [мәнфәгатьләрен кайгыртыр] өчен [мәйданга] чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысы сез булдыгыз [Ий Мөхәммәд өммәте! Аллаһының мәңгелек гыйлемендә дә, Ләүхүл-Мәхфүздә дә бу саклана]. Яхшы гамәлләрне әмер итәсез, начар гамәлләрдән тыясыз һәм Аллаһыга ышанасыз».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Әйе, Ислам дине артына яшеренеп, начарлык кылып йөрүчеләр дә бихисап. Үзләрен мөселман дип атап, башкаларны алдалап, башка дин вәкилләрендә Ислам дине хакында дөрес булмаган фикер булдырып йөрүче монафикълар пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында да булганнар, бүген дә бар, ахырзамангача да булачак. Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә барыбызны да кылган гамәлләребезгә, ниятебезгә карап хөкем кылачак. Җаныбыз тәнебездән аерылып чыкканчы, без Ислам диненең саф дин икәнен башкаларга да җиткерү өчен тырышып яшәргә тиешбез. Динебезне үзләренең шәхси максатларында файдаланырга тырышучылар безләрдән түгел. Шуңа да дингә килүчеләр, Ислам дине нигезләрен өйрәнә генә башлаучылар остазларны игътибар белән сайласын иде. Ислам динендә кан коюга, үтерүгә, экстремистлыкка чакыру юк һәм булырга мөмкин түгел. Ислам дине кешене башка дин тотуы, башка милләттән булуы өчен генә үтерүне, аңа җәрәхәт салуны

катгый тыя. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга явызлык кылырга түгел, хәтта гөнаһка илтергә мөмкин булган эшләргә якын килергә дә кушмый. Кеше үтерү – зур гөнаһ, хакыйкый мөселман кешесе моны яхшы белә, ул Аллаһы Тәгалә ләгънәтеннән, мәңгелек җәһәннәм утыннан курка һәм бу адымга бармый.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَّا يَنْهَاكُمُ اللَّهُ عَنِ الَّذِينَ لَمْ يُقَاتِلُوكُمْ فِي الدِّينِ وَلَمْ يُخْرِجُوكُم مِّن دِيَارِكُمْ أَن تَبَرُّوهُمْ وَتُقْسِطُوا إِلَيْهِمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُقْسِطِينَ

**«Аллаһы сезне дин өчен сезгә каршы сугышмаганнарга һәм сезне йортларыгыздан куып чыгармаганнарга карата игелекле булудан һәм гадел эш итүдән тыймый. Һичшиксез, Аллаһы гадел булганнарны сөя [һәм алардан разый була]».**

«Мүмтәхәнә / Сыналучы хатын», 60:8

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, игътибар итегез әле: Раббыбыз мөселманнарга үзебезгә, гаиләбезгә, динебезгә, илебезгә кылыч күтәреп килмәгән кешегә карата, аның нинди дин тотуы, кайсы милләттән булуына карамастан, яхшы мөнәсәбәттә булырга өнди.

Берәр начар гамәлгә карата «дөрес эшләгән» дип фикер йөртү мөселманлык билгесе түгел. Инде андый начар гамәлләрдә катнашу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Без – мөселманнар көн дә кечкенә генә булса да яхшылык кылу белән генә чикләнеп калмыйча, үзебезне явызлыкка каршы көрәшкә дә багышларга тиешбез. Яхшылык башка яхшылыкларны алып килгән сыман, начарлык яңа начарлыкларга китерә. Мисаллар өчен ерак йөрисе юк, мөхтәрәм кардәшләр. Күпер салдыкмы – аның аркылы узган һәр кешенең рәхмәте күперне төзүченең гамәл китабына язылып бара. Ә инде әгәр хәмер сату белән шөгыльләнәбез икән: шул хәмерне эчеп, кем нинди яманлык кыла, шул гамәлләр өчен хәмерне сатучыга да җавап бирәсе булачак. Экстремистлыкка, кеше үтерүгә, фетнә чыгаруга өндәүче дә, хәтта үзе бу

эшләрдә катнашмаса да, бу гамәлләрне үз куллары белән кылган сыман булачак. Ислам дине – гаделлек дине. Рәхимле вә Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә бу фани дөньяда барлык кешеләрне тигез яратса да, Ахирәттә кылган гамәлләребезгә һәм уй-ниятләребезгә карап, кемнәрнедер мәңгелек җәннәтле, кайсыларыбызны җәһәннәмле итәчәк. Раббым, Үзең сакла!

Террорчылык белән экстремизмны Ислам диненә бәйләп аңлату – хаталы һәм бик куркыныч күренеш. Изге Китабыбыз Коръән, сөекле Пәйгамбәребезнең тормышы, хәдис-шәрифләре мөселманнарга шуны инандыра: Ислам дине мөселманнарны эшләрендә һәм гамәлләрендә күндәмлеккә, изгелеккә чакыра. Әхлагыбызны төзәтергә, яхшылыклар эшләп яшәргә тырышырга, бер мәхлүкатка да зыян салмаска тиешбез. «Кем ул мөселман?» – дигән сорауга, «Мөселманның кулыннан да, теленнән дә башка кешеләргә зыян килмәс», – дип җавап бирелә. Шуңа да Ислам әхлагы террорның һәм экстремизмның чыганагы түгел, ә хәл ителүедер.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит.

*Рәдиф хәзрәт Тимергалиев,*

*Кукмара районы имам-мөхтәсибе*

*22 нче сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Пәйгамбәребезнең мәүлиде

Бөтен галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Аллаһы Раббыбызга биниһая хәмед-сәна, шөкраналарыбыз булса иде. Безнең өчен һәр хәлебездә иң күркәм үрнәк булган нурлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһеленә, сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз ирешсә иде.

Рабигыль-әүвәл аеның 11 еннән 12 сенә булган кич – Ислам дөньясында зур тантана, бөтен дөнья мөселманнарының мөбарәк бәйрәме ул. Нәкъ менә шушы көндә безләрне караңгылыктан нурга, тәүфикъ-һидаятькә алып чыккан сөекле Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгән. Бу көндә кешелек тарихында иң мөһим һәм иң олуг урын алып торган шәхес дөньяга аваз салган.

Без һәрдаим Расүлуллаһның һәр гамәле, хәрәкәте, үз-үзен тотышы адәм балалары өчен үрнәк, бүләк булуы хакында истә тотарга тиешбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында Раббыбыз:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек»,** – дип әйтә.

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Әйе, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм билгеле бер халыкка гына түгел, ә барлык кешелек өчен, алай гына да түгел, бөтен галәмнәр өчен рәхмәт булып җибәрелде. Ул барлык мәхлүкъларга үрнәк, нәсыйхәтче,

һидаятькә чакыручы вазифасын башкарды. Расүлуллаһ килгәч, җәмгыятьтә «тамыр җәйгән» тәртипсезлек, гаделсезлекләргә нокта куелды. Еллар, гасырлар дәвамында барган бу золымлыклар төбе-тамыры белән алып ташланды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятимнәрнең, мескеннәрнең, ярдәмгә, яклауга мохтаҗ булучыларның, көчсезләрнең яклаучысына әйләнде, аларның күз яшьләрен сөртте, күңел түрләренә өмет, ышаныч, ярату дигән күркәм гөлләрнең орлыгын чәчте. Бу юлда үзенә күп авырлыклар күрергә туры килсә дә, гаделсезлекләр белән очрашса да, рухының ныклыгы, Раббысына тәвәккәллеге аңа артка чигенергә, бирешергә бирмәде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бүген дә безнең күңел түрләребездә, ничәмә-ничә еллар үтсә дә, аның нәсыйхәтләре безгә маяк булып тора.

Җәмәгать, әгәр без кемне дә булса яратабыз икән, аның тормышын өйрәнәбез, аны еш искә алабыз. Бүгенге көндә күп кеше танылган шәхесләрнең, «йолдыз»ларның тормышын өйрәнү, аларны үзләренә үрнәк итеп алу белән мәшгуль. Гәрчә бу кешеләрнең күбесе шәхсән безнең өчен дә, кешелек өчен дә әһәмиятле роль уйнамаска мөмкин. Шуңа да карамастан, без аларга вакытыбызны, игътибарыбызны исраф итәбез. Уйлап карыйк әле: Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешелек тарихында нинди урын алып тора соң? Ул безне нәрсәләргә өйрәтте? Безне ниләрдән тыйды? Нинди гамәлләрдән саклап калды?

Җәмәгать, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә иң кадерле бүләк – Ислам дине, Раббыбызга иман китерү дигән нигъмәтләр белән килде. Әгәр берәү безгә кыйммәтле бүләк белән килсә, аңа карата мөнәсәбәтебез нинди булыр иде икән? Сүз дә юк, без аңа да бүләк әзерләргә теләр идек, аны еш искә алып, рәхмәтле булып яшәр идек. Ә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм алып килгән бүләкләрнең бәһасе гаять зур һәм ул кешелек өчен куйган тырышлыкны әйтеп бетереп булмастыр.

Үзебезгә үрнәк итеп алган шәхесләр хакында тагын шуны да әйтеп үтик: кайберләренә без гомер буе сокланып, аларга кызыгып, үзебезгә аларны үрнәк итеп, аларга охшарга тырышып яшибез, әмма бу кешеләр безнең бу җир йөзендә яшәвебезне хәтта белмәскә дә мөмкин, ә без аларга күпме вакытыбызны багышлыйбыз, аларны күңелебездә йөртәбез, телебездән төшермибез. Ә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм инде бу дөньяда яшәгәндә үк өммәте өчен дога кылган, аның өчен кайгырган, Раббыбыздан булган хата-кимчелекләребезне гафу итүен сорап ялварган кеше. Һәм дәһшәтле булган Кыямәт көнендә дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне ташламаячак. Бу көндә адәм балалары бер-берсен күрмәгән, аяклар куркудан калтырап торган вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне яклар, безгә шәфәгатьче булыр, иншәАллаһ.

Ә без, үз чиратыбызда, безнең өчен шулкадәр тырышлык куйган Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата нинди гамәлләр кылырга тиешбез соң? Җәмәгать, безнең гадәти вакытларда да, һәм бигрәк тә мәүлид аенда, кичендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күпләп салават-шәрифләр ирештерүебез күркәм гамәл булыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенә салават сүзләрен ирештерүнең фазыйләтен ассызыклап, болай дип әйткән: «Кем миңа бер салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун салават әйтер, ун хатасын сөртер һәм аны ун дәрәҗәгә күтәрер»[1];

«(Бүтәннәрдән) ешрак салават әйткән кешеләр Ахирәт көнендә миңа башкалардан якынрак булыр»[2];

«Кыямәт Көнендә кешеләр арасында миңа иң якыннары булып, миңа иң күп салаватлар һәм сәламнәр әйтүче булыр»[3].

---

1 Имам Ән-Нәсаинең хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әт-Тирмизинең хәдисләр җыентыгыннан.

3 Шунда ук.

Моннан тыш, Расүлебезгә салаватлар әйтүче кешенең холкы күркәмләнә, ул начар гадәтләрдән арына, Аллаһының ризалыгына ирешә, ике дөнья бәхетенә лаек була һәм тормышына бәрәкәт иңә.

Ислам динендә мәүлид кичәсен билгеләп үтү гадәте бар. Рабигыльәүвәл аенда мөселманнар күркәм мәҗлесләрдә җыелып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яшәү рәвеше, әхлагы турындагы аятьхәдисләрне укыйлар, салаватлар әйтәләр, догалар кылалар.

Әмма, кызганычка, кайбер кешеләр, Коръәнне һәм хәдисләрне дөрес аңламыйча: «Мәүлидне уздыру куркыныч бидгать», – дип әйтәләр. «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре заманында Мәүлид бәйрәме бер дә үткәрелмәгән», – дип, кешеләрне бу гамәлнең бидгать, ягъни яңалык кертү икәненә ышандырырга тырышалар. Моңа дәлил итеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Насаралар Гайсәне олылаган кебек, мине алай олыламагыз», – ягъни илаһилаштырмагыз, дигән хәдисен китерәләр. Бу хәдискә таянып, Мәүлидне Раштуа яисә тагын да начаррак гамәл – потка табыну белән чагыштыралар.

Әлеге фикер дөреслеккә туры килми. Беренчедән, сәхабәләр заманында билгеләнгән көнне җыелырга һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында сөйләргә, ишетергә ихтыяҗ булмаган, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тарафдарлары аны һәркөнне күргәннәр һәм һәрвакыт аның янында булганнар, аның нәсыйхәтләрен ишетеп торганнар. Бер тапкыр Аллаһы Тәгаләнең Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһедән: «Син Аллаһыдан соң кемне күбрәк яратасың?» – дип сораган. Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Алдан үземне, аннары сине, йә, Расүлуллаһ», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, Гомәр, синең ихласлыгың зәгыйфь», – дигән. Шуннан соң Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Алай булгач, Аллаһыдан соң, дөньядагы бөтен

нәрсәдән күбрәк, сине яратам!» – дигән. «Менә хәзер инде синең ихласлыгың көчле», – дип әйткән Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Ибне Һишам Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турындагы китабында: «Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне шулкадәр нык ятратканнар ки, хәтта азанда «Мөхәммәд Расүлуллаһ» дигән сүзләр яңгырагач, аларның күңелләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт белән тула һәм алар елый башлыйлар иде», – дип язган.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң һәрвакыт мөселманнарны намазга чакыручы Билял радыяллаһу ганһе нәкъ менә шушы сәбәп аркасында азан әйтүен дәвам итә алмаган. Ул азан сүзләрен әйткәндә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен телгә алгач, елый башлаган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм гади кеше булмаган, ул бөтен мәхлүкъләр өчен Аллаһы Тәгаләнең сайланган Расүле иде. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ ۚ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмыйк! Әгәр без сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтенә иярсәк, аның тормышыннан үрнәк алып яшәсәк, иншәАллаһ, Раббыбызның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешербез. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Пәйгамбәребезнең дөньяга килгән көнен билгеләп үтүнең гаебе булмауга тагын бер дәлил – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә туган көнендә, ягъни дүшәмбе көнне ураза тота торган булган. Аннан: «Йә, Расүлуллаһ, ни өчен син дүшәмбе көнне ураза тотасың», – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Мин бу көнне тудым һәм бу көнне миңа вәхи иңдерелде»[1], – дигән. Белгәнебезчә, ураза тоту – ул Ислам терәкләренең берсе. Моннан күренә ки, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең туган көнен гыйбадәттә үткәргән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, безгә дә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәүлиден искә алып, бу көнне күпләп салават-шәрифләр әйтү хәерле булыр. Белүебезчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү бик тә күркәм, фазыйләтле гамәл булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү – мөселманнарның аңа карата яратуларын, рәхмәт һәм хөрмәт хисләрен, Расүлебезнең Кыямәт көнендә шәфәгатенә өметләнүен белдерүе ул.

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем булса да миңа бер салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун салават булдырыр, кем 10 салават әйтсә – Аллаһы Тәгаләдән 100гә ирешер. Кем миңа 100 салават әйтсә – Аллаһы Тәгалә аңа икейөзлелектән котылуны һәм уттан котылуны насыйп итәр һәм Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аны шәһитләр белән бергә булдырыр», – дигән.

Хәтта шундый риваять тә бар: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабере янында Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәкил итеп куелган фәрештә торадыр. Ул фәрештә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә, аның исемен искә алганнар белән салават әйткәннәрнең авазларын ишетеп торыр. Салават әйтелү белән, ул фәрештә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Сиңа фәлән улы яки кызы фәлән салават әйтте»,– дип җиткерер.

Бүгенге көндә Мәүлидне бәйрәм итү гадәтләре кайтарыла башлады. Галимнәр бу турыда: «Мәүлид уку – Исламның бик яхшы һәм файдалы гадәте. Ул мөэминнәр арасындагы аралашу, аларның иманы өчен ышандыргыч дәрес, кешеләр йөрәгендә Аллаһыга һәм Аның соңгы расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт уяту», – дигәннәр.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Расүлебез салләлаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтенә ияреп, аны олылап яшәүләребезне, Кыямәт көнендә дә Пәйгамбәребезнең шәфәгатенә ирешүләребезне насыйп итсә иде, телебездән салават-шәриф сүзләре төшмәсә иде. Раббыбыз белеп һәм белми кылган хата-кимчелекләребезне гафу әйләсә иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә,

иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*29 нчы сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Олыларны хөрмәт итү

Бөтен галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Аллаһы Раббыбызга биниһая хәмед-сәна, шөкраналарыбыз булса иде. Безнең өчен һәр хәлебездә иң күркәм үрнәк булган нурлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһеленә, сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз ирешсә иде.

Изге Коръәнебездә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә ата-ана хакында, аның олуглыгы, дәрәҗәсе турында бик күп сөйләнә.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип хәбәр бирә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ

**«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яратучың буларак] Миңа һәм [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа [булачак]».**

«Локман», 31:14

Аллаһыны таныган, Исламны бөтен барлыгы белән кабул иткән кеше ата-анасын рәнҗетми, аларга карата мөнәсәбәттә сак була, бу мәсьәләгә

җитди карый. Шулай да, кызганычка, соңгы вакытта нәкъ менә диндә булган яшьләр арасында ата-анага кырын карау очраклары еш күзәтелә башлады. Моның сәбәбе булып, үзләре намазга баскан, мәчеткә йөри башлаган яшьләребезнең диннән ерак булган ата-аналарын саннамаулары тора. Мин ата-аналарның балаларын диннән биздерергә теләү очраклары турында әйтмим. Кызганычка, андый күренеш белән дә еш очрашырга туры килә. Сүз – ата-аналарның балаларының диндә булганын хуплый торып та, балаларның өлкәннәргә өстән караулары, белемсезлектә гаепләүләре турында бара.

Аллаһыга шөкер, бүгенге көндә теләге булган кеше өчен дини белем алуда бернинди дә каршылыклар юк, дин тотуны да тыймыйлар. Әмма кайчандыр андый мөмкинлек булмаган. Һәм шуңа күрә бүгенге көнге өлкән буын вәкилләре әлеге мөмкинлектән мәхрүм калган. Бәхеткә, күпләр диндә булуның мөһимлеген аңлап, Исламга кайта, намазга баса башлады. Әмма кайберәүләр әле моннан ерак. Һәм моның өчен аларны түбәнсетергә, кимсетергә, бигрәк тә алардан йөз чөерергә кирәкми. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм диндә булмаганнар белән аралашуның күркәм мисалы булып тора. Ул беркайчан да кешеләрне аермаган, бигрәк тә югарыдан карап, син гөнаһлы инде, сине Аллаһы кичермәс, дип фикер йөртмәгән.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللَّهِ لِنتَ لَهُمْ ۖ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ ۖ

**«[Расүлем! Өммәтеңә карата сиңа] Аллаһыдан [бирелгән кызгану һәм] шәфкать белән син аларга йомшак булдың. Әгәр дә дорфа, каты күңелле булсаң, алар синең яннан таралып киткән булырлар иде...»**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Бу аятьтә диндә булган кешенең янәшәдәгеләргә аеруча да игътибарлы булырга тиешлеге турында сүз бара. Ә без тормыш биргән, тәрбияләп үстергән ата-аналарыбызга бигрәк тә яхшы мөгамәләдә булырга, дингә йомшаклык, күркәмлек белән чакырырга тиешбез.

«Җәннәт әниләрнең аяк табаны астында» дигән хәдисебез билгеле. Кеше җәннәткә әнисе ризалыгы аша керә, дигән сүз бу. Берәү көне-төне гыйбадәттә булып, әнисенә йомшаклык күрсәтмәсә, гыйбадәт кылуының файдасы булырмы?!

Биредә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен искә төшерү урынлы булыр: «Бер бик тәкъвалы Җүрәиш исемле кеше кырга чыгып, шунда үзенә кечкенә генә йорт салып, көннәрен һәм төннәрен шул йортта гыйбадәт кыла торган булган. Бер көнне намазда булганда, аның ишегенә әнисе килеп: «Улым ач, бу мин – әниең, йөзеңә карыйсым килә», – дигән. Бу егет, намазмы, әниме, дип уйлап, намаз укуны хәерлерәк күргән. Икенче, өченче көнне дә шулай ук кабатланган. Егет кеше һаман ишекне ачмаган. Шуннан соң әнисе күңеле калып: «Минем йөземә карыйсың килмәде, инде зиначы хатынның йөзен күрерсең», – дип әйткән.

Якындагы шул җирдә бер көтүче малын көтеп йөри икән. Аның янына бер зиначы хатын килеп йөргән. Көннәрдән бер көнне бу хатын әлеге көтүчедән бала тапкан. Аны шул шәһәрнең казыена алып барганнар. Казый аннан: «Балаң кемнеке?» – дип сораган. Теге хатын: «Җүрәишнеке», – дип җавап биргән. Казый Җүрәишнең йортын җимереп, үзен монда алып килергә боерган. Аны алып килгәч, казый: «Син тәкъва иясе булып йөрисең, ә үзең шундый зур гөнаһ кылгансың», – дип, аны җәзага тартачагын әйткән. Шулчак Җүрәиш елмаеп җибәргән. Казый сәбәбен сорагач, Җүрәиш: «Менә мин өч көн рәттән әниемне йортыма кертмәдем, намаз укуым белән мәшгуль булдым. Шулчак ул, минем йөземне күрәсең килмәсә, зиначы хатынның йөзенә багарсың», – дигән иде. Аллаһы Тәгаләнең хикмәтенә таң калып елмайдым, дип җавап биргән. Моннан

соң казый Җүрәишнең йортын торгызырга һәм аны тынычлыкта калдырырга боерган.

Әлеге кыйссадан күрүебезчә, адәм баласы гыйбадәткә бирелеп, ата-ана хакын онытырга тиеш түгел. Әлбәттә, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу иң беренче урында тора. Әмма ата-анага игелек күрсәтү – безнең изге бурычыбыз ул. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا

**«[Ий коллар!] Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, [бертуганнар һәм агалар кебек] якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, [нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән] якын күршегә, [нәселдәшлеге яки өе] ерак күршегә, [ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек] янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә [коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә] игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер [булганы өчен туган-кардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган] һәм [өстенлекләрен санаган] мактанчык кешеләрне сөйми».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Коръәндәге күркәм мисалга тукталыйк. Ибраһим галәйһиссәламнең әтисе потлар ясаучы һәм аларга табынучы кеше булса да, ул әтисенә катылык күрсәтмәде, ата хакын олылады. Ибраһим галәйһиссәлам әтисенә нәсыйхәтләр бирүдән туктамыйча, аңа йомшак мөгамәлә күрсәтте. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

إِذْ قَالَ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ لِمَ تَعْبُدُ مَا لَا يَسْمَعُ وَلَا يُبْصِرُ وَلَا يُغْنِي عَنكَ
شَيْئًا ﴿٤٢﴾ يَا أَبَتِ إِنِّي قَدْ جَاءَنِي مِنَ الْعِلْمِ مَا لَمْ يَأْتِكَ فَاتَّبِعْنِي أَهْدِكَ
صِرَاطًا سَوِيًّا ﴿٤٣﴾ يَا أَبَتِ لَا تَعْبُدِ الشَّيْطَانَ ۖ إِنَّ الشَّيْطَانَ كَانَ لِلرَّحْمَٰنِ
عَصِيًّا ﴿٤٤﴾ يَا أَبَتِ إِنِّي أَخَافُ أَن يَمَسَّكَ عَذَابٌ مِّنَ الرَّحْمَٰنِ فَتَكُونَ
لِلشَّيْطَانِ وَلِيًّا ﴿٤٥﴾ قَالَ أَرَاغِبٌ أَنتَ عَنْ آلِهَتِي يَا إِبْرَاهِيمُ ۖ لَئِن لَّمْ تَنتَهِ
لَأَرْجُمَنَّكَ ۖ وَاهْجُرْنِي مَلِيًّا ﴿٤٦﴾ قَالَ سَلَامٌ عَلَيْكَ ۖ سَأَسْتَغْفِرُ لَكَ رَبِّي ۖ
إِنَّهُ كَانَ بِي حَفِيًّا

**«Менә ул атасына әйтте: «Ий әтием! [Ялваруларыңны] ишетмәгән, [үзләренә баш июләреңне] күрмәгән һәм сине бернәрсәдән дә коткара алмаган нәрсәләргә ни өчен табынасың? Ий әтием! [Яратучының берлеге хакында] сиңа килмәгән гыйлем миңа килде. Син миңа ияр дә, мин сине туры юлга кертим. Ий әтием! Шайтанга табынма. Шайтан – Рахманга каршы баш күтәрүче бит [әгәр аңа иярсәң, нигъмәтләреңнән мәхрүм ителерсең]. Ий әтием! Һичшиксез, мин Рахманнан сиңа бер газап кагыласыннан һәм синең шайтанга якын булачагыңнан куркамын. [Атасы әйтелгән нәсыйхәтләргә һич тәэсирләнмичә] Әйтте: «Ибраһим! Әллә син минем илаһларымнан йөз чөерәсеңме? Әгәр [бу сүзләрдән] ваз кичмәсәң, һичшиксез, сиңа ташлар белән атармын. Мине озак вакытка калдыр [һәм сине күзем күрмәсен]! [Ибраһим [галәйһиссәлам] Әйтте: «Сәлам сиңа! Синең [һидаятькә ирешеп гафу ителүгә лаек бер хәлгә килүең] өчен Раббымнан ярлыкау сораячакмын. Ул миңа карата бик шәфкатьле булды».**

«Мәрьям», 19:42–47

Аллаһы Тәгалә Изге Китапта пәйгамбәр булып сайланган затның хәтта потка табынучы атасына да йомшак сүз белән килгәнен, каты бәрелмәгәнен, аннан йөз чөермәгәнен ассызыклый. Шуңа да кичә генә намазга өйрәнеп, бүген әти-әниләрен дин тотмауда гаепләүче яшьләр дөрес эшләмәгәнлекләрен аңласыннар иде. Бәлки аларга ата-аналарының диндә булмавы сынау рәвешендә бирелгәндер. Кызганычка, моны күпләр аңламый.

Ата-анага хөрмәт, аларны олуглауның әһәмияте турында Изге Китабыбызда бик күп урыннарда искә алынганын күрдек. Алдагы аятьтә ата-анага авыр сүз әйтү турында гына түгел, хәтта «уф» сүзен әйтүнең дә шелтәләнгән гамәл икәнен күрәбез. «Әл-Исра» сүрәсендә болай дип әйтелгән:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾ وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек [кылырга] әмер итте. [Ий кеше!] Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең яныңда картлыкка ирешсә, аларга [канәгатьсезлек белдереп]: «Уф!» – дип тә әйтмә. [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да] Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт. Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]: «Ий Раббым! [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] Алар кечкенә чагымда мине [зур бер шәфкать белән] үстергәннәре кебек, Син дә аларга [бакый рәхмәтең белән] мәрхәмәт ит», – дип әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23–24

Аллаһы Тәгалә барыбызга да динебезне дөрес аңлап, якыннарыбызга нәсыйхәтләр әйтеп, аларның дингә килүенә сәбәпче булырга насыйп итсә иде, кылган гамәлләребез ихластан һәм дөрес булып, ата-аналарыбыз каршындагы бурычларыбызны үтәп, ризалыкларына ирешә алсак иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*6 нчы октябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Нәрсә ул фитрый иман?

Барча мактаулар һәм сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Адәм баласы һәрдаим Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген күрсәтә торган дәлилләрне тоемлап яши. Ләкин күпләр аларны күрергә теләми. Бер чит ил университетында кечкенә балаларга курчак әкияте күрсәткәннәр. Курчакның берсе яхшы холыклы булган, уңай рольне уйнаган, ә икенчесе начар, тискәре холыклы булып, гел яхшы курчакны рәнҗетә торган булган. Соңыннан балаларга бер курчакны сайлап алырга кушканнар. Күпләре игътибарсыз гына карап утырсалар да, барысы да уңай рольне уйнаган курчакны сайлаган. Бу мисалдан баланың күңелендә изгелеккә, яхшылыкка омтылыш инде туган вакытында ук булуы күренә. Кечкенә вакытыннан ук адәм баласы нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен белә. Җир йөзенә килгән һәр кеше, кечкенә вакытыннан ук яхшыны начардан аеру сәләтенә ия булган кебек, аңлатып бирә алмаслык, гадәттән тыш көчкә дә ышана. Әгәр адәм баласы җир йөзенә шундый сыйфатлар белән җибәрелә икән, димәк, бу сыйфатларны безгә күпкә акыллы, гыйлем иясе булган Зат бирә.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

فِطْرَتَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا ۚ لَا تَبْدِيلَ لِخَلْقِ اللَّهِ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

**«[Ий мөэминнәр! Сез дә] Аллаһының [Ислам] фитратына [бергә нык итеп ябышыгыз], Ул бөтен кешеләрне аның белән яратты. [Нәфеснең начар теләгенә ияреп һәм шайтанның вәсвәсәләрен кабул итеп] Аллаһының яратуына [каршы кылыначак] бернинди үзгәртү булмас. [Бернинди кимчелеге булмаган] Туры дин менә бу, ләкин кешеләрнең күбесе белмиләр».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:30

Әйе, адәм баласы кайсы илдә, нинди шәһәрдә дөньяга килүенә, нинди халыктан булуына карамастан, бу дөньяга алда әйтелеп киткән сыйфатлар белән туа. Менә бу сыйфат, бу гыйлем «фитрый иман» дип атала да инде. Бу Аллаһы Тәгаләне табарга һәм танырга ярдәм итә торган, тумыштан бирелгән табигый тойгы, эчке сиземләү. Мисал өчен, яңа туган бала шул ук мизгелдә әнисенең күкрәгенә тартыла. Әмма күкрәк сөте белән ни рәвешле туклана-сын ул каян белә?! Аның боларны өйрәнергә вакыты да булмады бит әле. Бу гыйлемне аңа Аллаһы Тәгалә салды һәм җир йөзенә җибәрде.

Яратучыбызга ышану – тумыштан килгән хис ул. Раббыбызны тану өчен, Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызны да шундый эчке сиземләү хисе белән яраткан. Әгәр кеше күңелендә булган хәбәр хакында бераз гына уйланса, олуг Затның барлыгына бик тиз инаначак.

Җир йөзендә күпсанлы диннәр, төрле ышанулар бар. Борынгы заманнарда гомер итеп, хәзерге вакытта юкка чыккан кавемнәрнең яшәгән җирләренә, шәһәрләренә күз салсак, аларның һәркайсында гыйбадәт кылу урыннары булганын күрербез. Әгәр тормышларын яхшырак итеп өйрәнсәк, аларның нindидер зур көч иясе булган, олуг затка табынулары ачыклана. Әгәр дә аларның күңелләренә үзләреннән күпкә камил булган, бик тә көчле затка омтылу тойгысы салынмаган булса, җир йөзендә күпсанлы диннәр, ышанулар булыр иде микән?! Билгеле, юк! Ләкин аларның барысы да Аллаһы Тәгаләнең барлыгын таный дип әйтеп булмый. Берәүләр – утка, кояшка, икенчеләр сыннарга һәм башкаларга табына. Бу мисал аларның

үзләрен ризыкландыручы, кояшы белән җылытып, яңгырларын яудырып торучы, гомер итәргә бар мөмкинлекләрне бирүче көчле Затка ышанганнарын раслый.

Уйлап карасак, адәм баласына аның күңеле һәрвакытта да дөньяга китергән Яратучы – Аллаһы Тәгалә барлыгын искә төшереп тора. Ачлык хисе ризык барлыгын, сусау хисе суның барлыгын исбатлап һәм аларны эзләргә мәҗбүр иткән кебек, күңелдәге эзләнүләр дә Аллаһы Тәгаләгә алып бара. Тумыштан бирелгән фитрый иманны аңлау өчен, тормышыбызга карау да җитә. Мисал өчен, өстәлдә ят ризык, акча, кием барлыкка килсә, аптырап калачакбыз. Аларны куллана башлаганчы, кем куйган, кем салган дип, бу әйберләр белән калдырган кеше арасында элемтә эзли башлыйбыз. Иртән уянып киткәч, йорт янында бер яңа машина тора, ди. Шул ук мизгелдә аңа утырып, кузгалып китмибез бит, машиналы булуны да инкяр итмибез, билгеле. Беренче булып безнең күңелдә кемнән, каян, ничек шулай булды, дигән сораулар барлыкка килә. Шуның кебек үк, 30–40 градуслы салкын кышлардан соң, җәйнең кызу, матур көннәрендә сабакларында кызарып утырган җиләк-җимешләр, алмалар һәм башка күп кенә тәмле, файдалы ризыклар каян пәйда булган, аларны кем үстергән, дигән сораулар да безне уйланырга мәҗбүр итә.

Бу уйларны бездә олуг көчкә ия булган Зат тарафыннан тумыштан ук бирелгән гыйлем тудыра. Җир өстендәге җанлы һәм җансыз булган һәрнәрсәнең Яратучысы бар. Галәмнәр, йолдызлар, кояш, планеталар, таулар, океаннар үзлегеннән генә барлыкка килмәгән. Боларны аңлауда, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышануда фитрый иман ярдәм итә дә инде.

Коръәндә:

أَمْ خُلِقُوا مِنْ غَيْرِ شَيْءٍ أَمْ هُمُ الْخَالِقُونَ

**«Әллә алар [яратылышларын җайга салып, аларны юктан бар иткән] бернәрсә булмыйча [үз көйләренә] яратылдылармы яки**

**алар үзләре [үзләрен] яратучылармы [Аллаһыны да, пәйгамбәрне дә танымыйлар]?»** – дип әйтелгән.

«Әт-Тур / Тур тавы», 52:35

Ышану һәм аңлау ул компьютерга куелган күрсәтмә кебек һәм кешедә дә шундый ук тәртиптә эшли. Ә инде ачыктан-ачык дәлилләрне күреп яки күрмичә Яратучыны инкяр итсәк, бу гамәл фитрый иманга каршы килә, аны сызып ата. Моннан шундый сорау туа: әгәр Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең барлыгын раслый торган хис, эчке сиземләү белән туган икән, ни өчен җир өстендә шулкадәр күп динсезләр, мәҗүсиләр гомер сөрә соң? Моның сәбәбе шунда: адәм баласы ирекле зат. Әйе, һәр кешегә сайлау иреге бирелгән. Күпләр ышана, ләкин кабул итми. Кеше барысын да аңласа, белсә дә, кыенлыгыннан, җаваплылыгыннан куркып, Аллаһы Тәгалә биргән ирегеn башка юлда куллана.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәр кеше фитрый иман белән, мөселман булган хәлдә дөньяга килә, ләкин соңыннан ата-аналары аны йә яһүди, йә насара яки мәҗүси итә», – дип әйткән.

Моңа тәрбияләнә торган гаиләнең, дусларның, әйләнә-тирә мөхитнең нинди булуы, эш урыны һәм башка сәбәпләр дә зур йогынты ясый. Шуңа да карамастан, фитрый иман кешене, туган вакытыннан алып, соңгы сулышына кадәр һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә этәрәчәк, чөнки адәм баласы бик тә мохтаҗ зат.

Коръәндә:

وَخُلِقَ الْإِنسَانُ ضَعِيفًا

**«...кеше зәгыйфь буларак яратылган»,** – дип әйтелә.

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:28

Табигый мохтаҗлык – ул караңгылык кебек. Караңгы бүлмәдә ут яктысына барган кебек, кеше дә иртәме-соңмы дин юлына таба атлаячак. Әмма бу вакытта иң куркынычы – соңга калу.

Камил затлардан булуына карамастан, адәм баласында кимчелекләр байтак. Мәсәлән, күрү, ишетү сәләте, гыйлем ягыннан булган кимчелекләрне алыйк. Күп кенә хайваннар безгә караганда яхшырак ишетә, күрә, кечкенә генә җан ияләре тизлек ягыннан күпкә җитезрәк булырга мөмкин.

Әлеге мисалларны күреп, фикерләү сәләтенә ия булган кешенең башында шундый уй барлыкка килергә тиеш: «Әгәр миндә күрү, ишетү сәләте бар икән, мине яратып бу дөньяга җибәргән Зат чиксез күрү, ишетү сәләтенә лаек булган олуг гыйлем Иясе булырга тиеш!» Әйе, Раббыбызның «Басыйр», «Сәмигъ» сыйфатлары моны исбат итә дә инде. Аллаһы Тәгалә Адәм баласына күрү, ишетү, сөйләшү сәләтен биргән икән, шулар ярдәмендә Яратучыбызның сыйфатларын аңлауны һәм аларга инануны җиңеләйтә.

Аллаһы Тәгаләнең барлыгын танырга ярдәм итә торган тагын бер нәрсә – ул кешенең табигате. Ачкыч белән йозак арасында төзеклек булган кебек, кешенең фитрый иманы белән Ислам дине арасында да төзеклек бар. Һәр кеше дә дөреслеккә, хаклыкка омтыла. Хаксызлыкны инкяр итеп, җинаятьчеләргә җәза бирергә омтылу хисе Кыямәт көне булачагына һәм анда һәр җан иясе кылган гамәлләре өчен җәзасын алачагына дәлил булып тора. Әгәр кемнән дә булса акча алып торып, ул бездән соңыннан арттырып кайтаруны таләп итсә, бу хәлнең дөрес түгел икәнен аңлыйбыз. Күңелдә безгә карата ниндидер җинаять эше кылынган кебек хис туа. Әйе, бу нәрсә Ислам дине буенча рибадыр, харамдыр. Бу мисалдан да аңлашыла: рибаның харамлыгы иң баштан ук күңелгә салынган була.

Әгәр дә Адәм баласы үзенең табигатенә игътибар итсә, Аллаһы Тәгалә дөньяга җибәргән вакытта ук күңел түренә беркетелгән билгеләрне аңлый башлар иде. Әгәр күзләрне йомып, берни дә күрергә теләмәсәк тә, күңел авазыбыз безне Аллаһы Тәгаләгә, үзенең Яратучысына алып барачак. Әгәр уйлансак, галәмнәрнең Хуҗасы булган Затның барлыгын күрсәтә торган билгеләрнең күбесе үзебездә, безнең эчке дөньябызга салынган. Ләкин, кызганычка, күпләр аны күрү сәләтеннән мәхрүмдер.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Март – Июнь

## Аксакаллар Татарстанның дини-туристик маршрутларын үстерү мәсьәләләре буенча күчмә киңәшмә уздырды

15-16 нчы март көннәрендә Татарстан мөфтиятенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов җитәкчелегендә республика аксакаллары Әтнә, Арча, Кукмара районнарындагы дини-туристик маршрутлар буенча күчмә киңәшмәдә катнашты. Дини-туристик маршрутлар борынгы мәчет биналары белән танышу, татар дин әһелләре һәм галимнәренең исемнәре белән бәйле урыннарда булу, милләт зыялылары җирләнгән каберлекләргә барып дога кылуны күздә тотты. Аксакаллар мәчет-мәхәлләләр катнашында татар-мөселман үзенчәлекләрен саклау буенча киңкырлы тәҗрибәне өйрәнде, рухи мирас һәм дини шәхесләрнең тормышын, иҗатын барлау үзәкләрендә, музейларда булды, махсус оештырылган күргәзмәләрне карады.

## Болгар ислам академиясендә Гамәлгә куючылар советы утырышы үтте

Шәгъбан аеның 25 нче көнендә (17 нче мартта) Казанда Болгар ислам академиясенең Гамәлгә куючылар советы утырышы узды. Җыелышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасарлары Илфар хәзрәт Хәсәнов, Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте администрациясе җитәкчесе Мөхәммәт Таҗетдин, шулай ук Татарстан Рәисе хакимияте вәкилләре, шул исәптән, ТР Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, белем бирү һәм фәнни оешмалар җитәкчеләре катнашты.

Утырыш барышында Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручы Айнур Тимерханов 2020-2022 еллардагы эшчәнлек нәтиҗәләре белән таныштырды. Аннан Болгар ислам академиясе ректорын сайлау белән бәйле мәсьәлә каралды. Нәтиҗәдә Гамәлгә куючылар советы карары белән әлеге уку йорты җитәкчесе итеп Татарстанның атказанган юристы, ТР Конституция судының элеккеге рәисе Фәрхәт Хөснетдинов сайланды.

Моннан тыш, киңәшмәдә Болгар фәнни-белем бирү кластерын төзү мәсьәләсе каралды. Аның концепциясен Россия Ислам мәгарифе советы рәисе, БИАнең беренче ректоры, РИИ һәм КИУ ректоры, Татарстан мөфтие урынбасары Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин тәкъдим итте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Рәфикъ хәзрәтнең әлеге тәкъдимен хуплап, тагын бер кат Болгар академиясе каршында Россиякүләм мөселман галимнәре (голәмәләр) шурасы һәм дини әдәбият экспертизасы буенча Бөтенроссия советын төзү мәсьәләсен күтәрде. Шулай ук ул академия эшчәнлегенә остазларны җәлеп итү һәм аларны саклап калу буенча комплекслы чаралар кертергә тәкъдим итте.

## Рамазан ае алдыннан Арча мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Шәгъбан аеның 26 нчы көнендә (18 нче мартта) Арча районы Көтек авылында яңа мәчет ачылды. Көтек авылының яңа мәчете борынгы мәчет урынында, авылның иң матур җирендә Көтек авылы фермеры Дамир Шакирҗанов тырышлыгы белән сафка баскан. Өстәвенә, саф чишмә сулы кое казылып, мәчет эченә кертелгән, авыл халкы сулы булган.

Яңа мәчеттә берьюлы 60 кеше намаз укый ала. Хәзерге вакытта хатын-кызлар өчен якшәмбе көннәрендә дәресләр алып барыла. Мәчет бүгенге көндә электр белән җылытыла һәм яктыртыла. Барлык уңайлыклар тудырылган тәһарәтханә эшли. Хәзерге вакытта Арча мөхтәсибәтендә 93 мәчет эшли.

## Рамазан алдыннан Коръән уку курсларын тәмамлаган мөселманнарга сертификатлар тапшырылды

Рамазан-шәриф аена әзерләнү максатыннан оештырылган дәресләрне КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге белгечләре үткәрде. Барлыгы 240 кеше Казанның 10 мәчетендә танылган татар галиме Әхмәдһади Максудиның «Мөгаллим сәни» китабы буенча дәресләр алды. Алар 18 дәрестә гарәп әлифбасын үзләштерде, тәҗвидне – Коръән уку кагыйдәләрен, Изге Китапка булган әдәпләрне өйрәнде.

## Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны үтте

Рамазан аеның беренче көнендә, Татарстанда күпьеллык гадәт буенча «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны игълан ителгән иде. Әлеге акция ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан авыру балаларга, аз керемле гаиләләргә һәм мохтаҗларга ярдәм йөзеннән оештырылды. «Зәкят» хәйрия фонды марафон кысаларында 7098 кешегә ярдәм күрсәтте. Шул исәптә: Татарстанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәүче 23 авыру балага тернәкләнү һәм дәвалау курслары өчен түләнде, мохтаҗлар файдасына 1 900 000 сумнан артык фитр һәм фидия җыелып, 29 аз керемле гаиләгә бирелде, 625 кеше, мәдрәсә шәкертләре һәм мөгаллимнәр, инвалидлар һәм башка мохтаҗлар 4,5 тонна азык-төлек белән тәэмин ителде. Моннан тыш, 45 махсус хәйрия ифтарында республиканың Казан шәһәреннән, Әлмәт, Арча, Кукмара, Питрәч, Ютазы районнарыннан 5040 мохтаҗ авыз ачты. Казанда социаль маршрутта 800 пассажир көне буе бушлай йөрде – чыгымнарны Фонд күтәрде. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм «Гаилә» мәчете янында җиләк-җимеш агачлары утыртылды. Луганск һәм Донецкидан килгән 581 качакка 300 килограммга якын 481 927 сумлык шәхси гигиена кирәк-яраклары һәм

көнкүреш химиясе бирелде. Ураза бәйрәме хөрмәтенә «Дуслык» социаль-тернәкләндерү үзәгендә тәрбияләнүче балалар һәм яшүсмерләр өчен хәйрия чарасы уздырылды.

## Галиев мәчетендә Рамазан аенда Коръән хәтем кылынды

Рамазан-шәриф аенда Казанның Галиев мәчетендә Коръән хәтем кылынды. Хафиз, Галиев мәчете мөәзине Нурмөхәммәд хәзрәт Исламов көн саен өйлә намазыннан соң бер җөзне, ягъни Коръәннең $^{1}/_{30}$ өлешен укып чыкты. Хәтем кылу Рамазан аеның соңгы көнендә төгәлләнде. Коръәнне хәтем кылуга һәркем кушыла алды: Нәзарәтнең «ДУМ РТ» телеграмм-каналында Галиев мәчетеннән турыдан-туры трансляция алып барылды.

## Рамазанда Нәзарәт махсус хәрби операция кырындагы солдатларга Татарстан мөселманнарыннан икенче гуманитар ярдәм илтте

Изге Рамазан аенда ТР мөселманнары Диния нәзарәте чираттагы гуманитар йөкне Луганск өлкәсендәге хәрби частьләрнең берсенә илтеп кайтты: анда Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар хезмәт итә. Бу – солдатларга илткән икенче йөк. Республиканың төрле почмакларында яшәүче мөселманнар тарафыннан якынча 2 тонна авырлыктагы йөк җыелды. Солдатларга Нәзарәтнең барлык мөхтәсибәтләре дә диярлек ярдәм итте. Бу юлы махсус хәрби операция кырына рацияләр, «повер-банклар», телефон батарейкаларын тутыру һәм башка төрле компьютер техникасы; медицина товарлары; кеше ташу өчен каркассыз җайланмалар (комплектка җайланмалар үзләре, эвакуация өчен трос, сүтеп алына торган махсус ыргак керә), медикаментлар, стериль бинтлар; 1000 пар җәйге оекбаш; шикәр, ярмалар, макароннар, хәләл тушенкалар, бал һәм төрле кайнатмалар җибәрелде. Солдатлар

туган якларыннан күчтәнәчләр җибәргән дин кардәшләребезгә һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә рәхмәт белдерде.

## «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 11 нче чыгарылышында 130 кеше намазга басты

Рамазан аеның 18 нче көнендә (9 нчы апрельдә) Казанда Нәзарәтнең иң мөһим проектларыннан берсе – намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип исемләнгән кыска вакытлы курслар тәмамланды. Шәкертләр 6 атна дәвамында «Сира», «Гакыйдә» фәннәре һәм тәһарәт, намаз, ураза, хаҗ гамәлләре буенча гыйлемнәрне колачлаган курсны үзләштерде. Башка еллардан аермалы буларак, бу чыгарылышта гаиләләре белән белем алучылар да күп булды. «Ислам. Беренче адымнар» проектының 11 нче курсын 130 кеше тәмамлады. Унбер сезон дәвамында әлеге курсларда 1078 кеше белем алды һәм намазга басты.

## Казанда Рамазан ае хөрмәтенә 30 нчы маршруттагы бушлай автобус йөрде

Рамазан аеның 23 нче көнендә (14 нче апрельдә), изге җомга көнендә, Казанда 30 нчы автобус Рамазан ае уңаеннан барлык кешеләргә түләүсез хезмәт күрсәтте. Акция кысаларында әлеге маршрутка караган бер автобуста иртәнге сәгать алтыдан (6:00) кичке сәгать алтыга (18:00) кадәр һәркем бушлай йөри алды. Изге айда казанлылар һәм башкала кунакларына мондый үзенчәлекле бүләкне Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды ясады – пассажирларның чыгымнарын фонд күтәрде. Бушлай автобусны танып алу өчен аның алгы тәрәзәләрендә «Рамазан мөбарәк булсын» һәм «Социальный маршрут БФ «Закят» дип язылган табличкалар урнашкан, ә салоны шарлар белән бизәлгән иде.

30 нчы маршрут Казанда иң озын маршрутларның берсе – ул Совет, Идел буе, Вахитов, Киров районнарын тоташтыра. Моннан тыш, автобус «Зәкят» хәйрия фондына баручылар өчен шәһәр үзәгеннән уза. Пассажирлар арасында «Зәкят» хәйрия фондына даими мөрәҗәгать итүчеләр, мохтаҗлар да бар. Көн дәвамында «Зәкят» фонды вәкилләре «Рамазан – изге гамәлләр ае» марафоны, «Зәкят» хәйрия фонды турында сөйләде, Ислам диненең матурлыгын, күркәмлеген күрсәтте. «Зәкят» хәйрия фонды генераль директоры Булат Мәрданов социаль маршрут юнәлешендәге хәйрия акциясенең беренче тәҗрибә икәнлеген, киләчәктә аны мөмкин булганча киңәйтәчәкләрен хәбәр итте.

## Казанда XI Республикакүләм ифтар узды

Рамазан аеның 25 нче көнендә (15 нче апрельнең кичендә) Казанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында XI Республикакүләм ифтар үтте. Чарага Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та кушылды. Бу юлы Татарстандагы иң зур авыз ачу мәҗлесе Рамазан аеның соңгы ункөнлегенә – гыйбадәт кылуда аеруча зур тырышлык күрсәтү вакытына туры килүе белән үзенчәлекле булды. Республикакүләм ифтарны Татарстан мөфтияте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында оештырды. Анда республиканың төрле почмакларыннан 10,5 мең кеше җыелды. Алар арасында мохтаҗлар һәм аз керемлеләр, җитәкчеләр, эшмәкәрләр, төрле төбәкләрдән килгән кунаклар һәм рәсми затлар бар иде. Ифтарга Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондыннан 200 мохтаҗ да килде. Казанлылар «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенә шәһәр яны поездлары белән махсус оештырылган бушлай рейс белән барып кайта алды.

## Рамазанның соңгы көнендә «Зәкят» фонды Казанда яңа аллеялар утыртты

Рамазан аеның соңгы 29 нчы көнендә (20 нче апрельдә) Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм «Гаилә» мәчете янында 30 төп алмагач, груша, слива агачлары утыртты. Үсентеләр Фондның үз акчасына садакаи-җәрия буларак сатып алынды. Садакаи-җәрия дип, мәчет-мәдрәсәләр, мәктәпләр, хастаханәләр төзетү, урманнар утырту, юл-күперләр салу, чишмә-коелар казу, Коръән бастыру кебек, кешеләргә гомерлек файда китерә торган гамәлләрне атыйлар. Садакаи-җәриянең әҗер-савабы кеше үзе үлгәннән соң да тукталмый.

## Галиев мәчетендә Ураза гаете узды

Шәүвәл аеның 1 нче көнендә (21 нче апрельдә) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм – Ураза гаетен билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Башкалада төп бәйрәм тантанасы Галиев мәчетендә узды. Гаеткә килгән мөселманнар, бәйрәм вәгазен тыңлап, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә намаз укыды. Галиев мәчетендәге бәйрәм чараларын «ТНВ Татарстан», «ТНВ Планета» телеканалы аша турыдан-туры карарга мөмкин булды. Туры эфир шулай ук Нәзарәтнең dumrt.ru сайтында һәм «Хозур ТВ»ның YouTube каналында да оештырылды.

## Казанда «Гает моңы» бәйрәме узды һәм «Рухи моң» бәйгесе җиңүчеләре бүләкләнде

Шәүвәл аеның 1 нче көнендә (21 нче апрельдә) Ураза бәйрәме көнне Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә «Гает моңы» бәйрәме үтте. Ул «Рухи моң» татар рухи мәдәниятне үстерү фестиваль-бәйгесенең гала-концерты да булып, анда бәйгегә нәтиҗәләр дә чыгарылды. Быел фестиваль Татарстанда

игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында «Рухи моң» иҗат берләшмәсе, Татарстан мөфтияте, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә тарафыннан дүртенче тапкыр оештырылды. «Тәртип» радиосы фестивальнең мәгълүмати партнеры булды.

Бәйге татар мәкаме һәм традицион мелодика калыпларын кайтаруны, татар халкының нигез кыйммәтләрен үз эченә алган рухи җыр жанрын баетуны, татар мәкаме белән азан әйтү культурасын булдыруны, татар теленең кулланылыш даирәсен арттыруны максат итеп куйды. 2023 елның февраль башында игълан ителгән конкурс «Дини җыр», «Мөнәҗәт», «Милли мәкам белән азан әйтү», «Вәгазь сөйләү» номинацияләрендә читтән торып үткәрелде. Бәйгегә Пермь крае, Самара, Курган, Төмән, Мәскәү, Омск өлкәләре, Чувашия, Башкортстан республикаларыннан һәм Татарстаннан 200гә якын видеоязма кабул ителде. Аларның күпчелеге «Мөнәҗәт» номинациясенә юлланды. «Дини җыр» номинациясендә 1 нче урынга – Ландыш Фазуллина, «Мөнәҗәт» номинациясендә ялгыз башкаручылар арасында – Рафис Шәйдуллин, ансамбльләр арасында «Җомга көн» ансамбле лаек булды. Фестиваль-бәйгенең гала-концертында җиңүчеләргә һәм призерларга акчалата бүләкләр тапшырылды.

## Казанда яшь мөслимә киленнәр өчен онлайн-курслар башланды

2023 елның 25 нче апрелендә Диния нәзарәтенең мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган проектларның берсе – «Яшь килен» курслары үз эшен башлап җибәрде. Әлеге проект 8 нче тапкыр тормышка ашырылып, дистанцион форматта узды. Бу курсларда катнашучыларның географиясен киңәйтергә: Казан, Мәскәү һәм Уфа, Чиләбе һәм Самара, шулай ук Дубай, Татарстанның шәһәр-районнарыннан, Башкортстаннан, Мәскәү, Оренбург өлкәләреннән, Казахстаннан 70 мөслимәне җәлеп итәргә мөмкинлек бирде.

Киленнәр мәктәбе Аллаһы Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүчеләр – 17 яшьтән алып һәм аннан өлкәнрәк, кияүдә булмаган кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырыла. Белем бирү курслары Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте һәм Ислам дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнгән. Мөслимәләр өчен бирдә академик белемнәргә ия, танылган остазлар һәм шәехләрдән никахта ир-хатынның бурычлары һәм хокуклары, мәһәр, никахлашу өчен хәерле ир сайлау, яшь гаиләдә проблемалар, балалар тәрбияләү, никахта җенси мөнәсәбәтләр һ.б. турында тәфсилле лекцияләр уздырыла. Кызлар никах, үзләренең хокуклары һәм бурычлары турында хакыйкый гыйлемнәр ала һәм үзләренә ир сайлаганда төптән уйланган карарлар кабул итәргә өйрәнә.

## Нәзарәттә Хәнәфи мәзһәбендә иң абруйлы хезмәтләрнең берсе — «Дүрр-әл-Мүхтәр»не заманча итеп, кыскартылган рәвештә әзерли башладылар

Шәүвәл аеның 7 нче көнендә (27 нче апрельдә) Диния нәзарәтендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин рәислегендә яңа зур фәнни хезмәтне әзерләп чыгару буенча эшче төркемнең беренче утырышы узды. Мөфтиятнең шәригать белгечләре һәм Голәмәләр шурасы әгъзалары алдында Хәнәфи мәзһәбендә иң абруйлы хезмәтләрнең берсе, ислам хокукы буенча фундаменталь фәнни әсәр – «Радд-әл-мүхтәр галәд-дүрр-әл-Мүхтәр»не заманча итеп, кыскартылган рәвештә гарәп, рус һәм татар телләрендә әзерләү бурычы куелды.

Күптомлы әсәр шулай ук «Хашият бине Габидин» исеме белән дә билгеле һәм XIX гасыр галиме, бөек дин әһеле, 46 фәнни хезмәт авторы Ибне Габидин Әл-Хәнәфи тарафыннан язылган. Фундаменталь китап фикһның (ислам хокукы) барлык бүлекләре буенча фәтвалар – дини карарлар җыентыгы

булып тора. Аның эчтәлеге белән Нәзарәтнең «Даруль ифта» бушлай электрон китапханәсендә танышырга мөмкин.

Нәзарәт белгечләренә шушы әсәрдә урын алган берничә мең фәтвалар арасында кануни яктан иң дөрес һәм көчле расланган, бүгенге көндә иң актуаль карарларны сайлап алырга туры киләчәк. Эшнең киләсе этабында хезмәт рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителәчәк.

## РИИда Ислам фәннәре буенча төбәк һәм татар теле буенча республикакүләм олимпиадалар узды

Шәүвәл аеның 7 нче көнендә (27 нче апрельдә) Россия ислам институтында мөселман уку йортлары шәкертләре арасында берьюлы ике интеллектуаль ярыш: Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча төбәк олимпиадалары һәм татар теле, әдәбияты һәм тарихы буенча республикакүләм олимпиада узды. Аларны Россия ислам институты, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды оештырды.

Ислам фәннәре буенча олимпиадада Россиянең 13 уку йортыннан 60 шәкерт катнашты. Алар арасында, Татарстан мәдрәсәләреннән тыш, Мәрьям Солтанова исемендәге ислам көллияте, Пермь ислам көллияте, Мәскәү ислам көллияте һ.б. бар.

Татар теле буенча олимпиадада Татарстанның барлык 8 мәдрәсәсе, Казан ислам университеты һәм Россия ислам институты шәкертләре катнашты. Алар татар теле, татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы өлкәсендә гыйлемнәрен тикшерде. Моннан тыш, татар әдәбияты буенча кызлар фәнни проект, егетләр вәгазь әзерләде.

## Нәзарәттә иң яхшы тышкы бизәлешкә «Нурлы Рамазан» бәйгесе җиңүчеләрен котладылар

Шәүвәл аеның 8 нче көнендә (28 нче апрельдә) Нәзарәттә Рамазан ае уңаеннан җәмәгать урыннары арасында иң матур бизәлештә ярышу буенча «Нурлы Рамазан» бәйгесе җиңүчеләрен котладылар. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин бәйгенең абсолют җиңүчесе булган Кукмара районының Туембаш авылындагы шәхси йорт хуҗалары – Сәетовлар гаиләсенә «ДУМ РТ Хадж» рәсми хаҗ операторыннан хаҗга юллама сертификаты тапшырды. Бу объект барлык сайлап алу критерийларына җавап бирә: ул бизәлештә Ислам һәм Рамазан ае символларын кулланган; гадәти булмаган бизәлеш; эстетик күркәмлеккә һәм мәгънәви төсмерләргә ия; хәзерге заман технологияләрен файдаланган. Әлеге шәхси йорт көндезен һәм төнлә бөтен урамны гирляндалар һәм «Рамазан – 2023» язуы белән яктыртып тора. Шулай итеп, барлык авыл халкына изге айның кыйммәтләрен искә төшерә. Лауреатлар дип табылган Лаеш мөхтәсибәте мәчете (ул башкалардан колачлылыгы һәм мәгънәви төсмерле булуы белән аерылып тора) һәм Казанда «МануФактура» кәһвахanәсе (аның керү юлы дизайнерлы бәйрәмчә бизәлеш белән яктыртылган) дипломнар һәм истәлекле бүләкләргә лаек булды. Калган катнашучыларга сертификатлар бирелде.

## Нәзарәт һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе коллективы Казанның Яңа татар зиратында өмә ясады

Шәүвәл аеның 8 нче көнендә (28 нче апрельдә) Нәзарәт һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе хезмәткәрләре Казанның Яңа бистә зиратында өмә ясады. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Ислам кабул итүгә 1000 еллык исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин җитәкчелегендә Татарстан Нәзарәте хезмәткәрләре һәм имамнары, мәдрәсә мөгаллимнәре һәм шәкертләре зиратның зур өлешен рәткә китерде, каберлекләрне чүп-чардан,

кипкән үләннәрдән һәм корыган агачлардан аралады, аллеяларны себереп җыештырды, кабер ташларын чистартты.

Өмә уздыру өчен Яңа татар зираты юкка гына сайлап алынмады. Беренчедән, биредә 3 нче майда традицион рәвештә Остазларны искә алу көне узачак, икенчедән, биредә 50 дән артык дин әһеле, мәгърифәтчеләр һәм галимнәр җирләнгән. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Әхмәдһади Максуди, Сөнгатулла Бикбулатов, Зәкәрия Минвәлиев, Габделхак хәзрәт Саматов, Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин бар. Ахырдан биредә җирләнгән дин әһелләре, күренекле мәгърифәтчеләр һәм остазлар рухына күмәкләп дога кылынды.

## Азнакайда Коръән укучыларның «Әсләм» республика бәйгесе узды

Шәүвәл аеның 9 нчы көнендә (29 нчы апрельдә) Татарстанның Азнакай шәһәрендә ир-атлар арасында алтынчы тапкыр Коръән укучыларның «Әсләм» республика бәйгесе узды. Бәйгене Татарстан мөфтияте, Көньяк-көнчыгыш төбәк казыяты, Азнакай шәһәре һәм Азнакай районы мөхтәсибәте, Азнакай районы хакимияте, Шакировлар гаиләсе оештырды. Бәйгенең төп максатларының берсе булып, иң яхшы Коръән-хафизны ачыклау, Коръәнне яттан белүне популярлаштыру максаты күздә тотылды.

Бәйгедә Казан, Түбән Кама, Чистай һәм Ульяновск шәһәрләреннән, Татарстанның Кукмара, Мөслим, Балтач, Ютазы, Әгерҗе, Биектау, Лениногорск, Бөгелмә, Лаеш, Тукай районнарыннан 50 дән артык кеше катнашты. Аларның белемнәрен КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән-хафизлар үзәге җитәкчесе, Ислам фәннәре докторы Габдерәшит хәзрәт Фәизов җитәкчелегендәге мәртәбәле жюри бәяләде. Бәйгедә җиңүчеләр – кыйммәтле бүләкләр һәм призлар, ә барлык катнашучыларга кызыксындыру бүләкләре тапшырылды.

## Казанның Яңа татар зиратында Остазларны искә алу көне узды

Шәүвәл аеның 12 нче көнендә (2 нче майда) мөселман дин эшлеклеләре, имамнар, мөгаллимнәр, зыялылар, киң татар җәмәгатьчелеге Казан шәһәренең Яңа бистә зиратына Остазларны искә алу чарасына җыелды. Алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде. Дога кылу мәрасименә килүчеләрне әлеге чараны 1998 елдан бирле оештыручы, аның программасын һәм Яңа бистә зиратындагы каберлекләр картасын төзүче, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе, Казанның «Ал мәчет» имам-хатыйбы Ильяс хәзрәт Җиһаншин каршы алды. Шулай итеп, быел 25 нче тапкыр уздырылган искә алу чарасында Чувашия Республикасы, Киров, Ульяновск өлкәләреннән дә дин әһелләре, мәдрәсә шәкертләре, иҗат әһелләре, мәрхүмнәрнең туганнары, хезмәттәшләре, алар юлын дәвам итүче имамнар – барлыгы 50 дән артык кеше катнашты.

Зиярәт кылу барышында Ильяс хәзрәт Җиһаншин мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга татар дөньясында билгеле шәхесләрнең каберлекләренә куар-кодлы табличкалар кую проектын тәкъдим итте. Заманча технология ярдәмендә бирердә җирләнгән йөзгә якын дин әһеле, мәгърифәтче һәм галим турында тулы мәгълүмат алып булачак. Шулай ук репрессия корбаннары булган, каберләре билгесез шәхесләрне (Шәһретдин Шәрәф, Кәрим Тинчурин, Һади Атласи, Мөхәммәдсадыйк Иманколый һ.б.) искә алу өчен әлеге зиратта бер билге куярга тәкъдим ителде, иске кабер ташларын җыеп саклау мәсьәләсе күтәрелде.

## Шәүвәл аеның 13 нче көнендә – 3 нче майда Татарстанда Хәтер көне узды

Шәүвәл аеның 13 нче көнендә, ягъни 3 нче майда, Татарстанда Хәтер көне үткәрелде. Татар халкы тарихында әлеге истәлекле дата республиканың

төрле мәчетләрендә билгеләп үтелә, әмма төп чаралар аеруча зурлап башкалада – «Кол Шәриф» мәчетендә уздырылды. Бу уңайдан Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы оештырган чарага Татарстанның төрле почмакларыннан аксакаллар, мөхтәсибләр, имамнар килде.

Хәтер көне өйлә намазы җитү вакыты белән көндезге сәгать 12:00дә башланып китте. Мәчеткә җыелган халык Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә җәмәгать белән өйлә намазы укыды һәм шуннан соң чараның төп өлешен уздырыр өчен Казан ханнары җәсәдләре җирләнгән мавзолей һәм Сөембикә манарасы янына юнәлде. Каберлек янында Татарстанның төньяк-көнбатыш төбәге казые, Яшел үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллин Коръәннән сүрәләр укыды, Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов Казанны алганда шәһит киткәннәр һәм динебез, халкыбыз һәм Ватаныбыз хакына төрле вакытларда һәлак булган татар халкының батырлары рухына дога кылды.

Хәтер көне ел саен Татарстан мәчетләрендә, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы тәкъдиме белән, Рамазан ае тәмамланганнан соң, 2 атна узгач, шәүвәл аеның 13 нче көнендә билгеләп үтелә.

## Казанда танылган мөселман тренеры Айрат Кәлимуллин истәлегенә джиу-джитсу буенча Бөтенроссия ярышлары узды

Шәүвәл аеның 17 нче көнендә (7 нче майда) Казанда «Ак барс» көрәш сараенда танылган мөселман тренеры Айрат Кәлимуллин истәлегенә ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында джиу-джитсу буенча бөтенроссия ярышлары узды. Турнирны ТР мөселманнары Диния нәзарәте ярдәме белән Татарстан Республикасы джиу-джитсу федерациясе оештырды. Ярышлар Айрат Кәлимуллин исеме белән аның күренекле спорт һәм тренерлык казанышлары истәлегенә багышланды.

Ярышларда бөтен Россиядән джитсерлар – 2005 елда туган һәм аннан өлкәнрәк, джиу-джитсу буенча 1 разрядтан түбән булмаган квалификациягә ия ир-атлар һәм хатын-кызлар катнашты. Спортчылар көрәш, файтинг, не-ваза һәм дуо-систем бүлекләрендә көч сынашты. Шунысы игътибарга лаек: ярышларда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Спортчылар, җиңүчеләр һәм призерлар арасында республиканың ислам уку йортлары шәкертләре шактый иде.

Айрат Дамир улы (30.04.1961 – 23.03.2022) – ТР джиу-джитсу Федерациясе президенты. СССРның җыелма командасын «ихтыярый уеннарга» (Игры доброй воли) әзерләү буенча тренерларның берсе булган (1992, АКШ). Ветераннар арасында джиу-джитсу буенча дөнья чемпионы (2013, БГӘ), самбо һәм дзюдо буенча спорт мастеры, джиу-джитсу буенча кара билбау иясе. Айрат Кәлимуллинның 2022 елда озакка сузылган авырудан соң вафаты Татарстан өммәте өчен авыр югалту булды. Аның укучылары Халыкара спорт ярышларында Татарстан һәм Россия данын яклауны дәвам итә.

## Чаллыда Нәзарәт Кубогына һәм хаҗ өчен татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XIV Бөтенроссия турниры узды

Шәүвәл аеның 17 нче көнендә (7 нче майда) Яр Чаллы шәһәрендә «Витязь» спорткомплексында Нәзарәт Кубогына һәм хаҗ өчен татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XIV Бөтенроссия турниры узды. Әлеге бәйге Татарстан мөфтияте, Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты, Россия һәм Татарстанның көрәш федерацияләре, Яр Чаллы мөхтәсибәте тарафыннан оештырылды. Турнирга 80гә якын спортчы килде. Һәр үлчәү категориясе буенча җиңүчеләр ачыкланды, алар кыйммәтле бүләкләр, диплом һәм медальләр алды. Шуннан соң үз үлчәү категорияләрендә беренче урынны алучылар хаҗга юлламага җирәбә уйнатуда катнашты. Җирәбәдә кул көрәшендә һәм татар милли көрәшендә җиңүчеләр катнашты. Хаҗга юллама белән кул көрәшендә

85 килограммга кадәр үлчәү авырлыгында җиңү яулаган Яр Чаллы егете – 27 яшьлек Булат Фаракшин лаек булды. Командалар арасындагы исәптә беренче урында – Яр Чаллы командасы.

## Урыссуда Россиякүләм Коръән бәйгесендә 16 яшьлек хафизә Айсылу Хаҗиева җиңде

Шәүвәл аеның 24 нче көнендә (14 нче майда) Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында «Халисә» IV Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе үткәрелде. Әлеге конкурс һәр елдагыча Татарстан мөфтияте, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казыяте, Ютазы мөхтәсибәте тарафыннан Ютазы районы хакимияте һәм Мәрданшиннар гаиләсе ярдәме белән оештырылды. Быел география киңәйде, хатын-кызлар, Татарстан һәм күрше Башкортостан район-шәһәрләреннән тыш, Уфа, Магнитогорск, Чиләбе шәһәрләреннән, Мәскәү һәм Пенза өлкәләреннән дә килде. Иң яшь катнашучыга – 8, иң олысына 38 яшь иде.

Бәйгедә барлыгы 60 кеше көч сынашты. Финалда 28 кыз 4 номинациядә белем һәм күнекмәләрен күрсәтте. «Коръәнне тулысынча яттан белү» номинациясендә беренче урынга Тукай муниципаль районының Күзкәй урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы 16 яшьлек Айсылу Хаҗиева лаек булды һәм гомрәгә юллама белән бүләкләнде. 7 җөзне яттан белү номинациясендә беренче урын алган Әминә Вәлиуллина (Уфа) – 50 мең, 5 җөзне иң яхшы белүче Вера Кәримова (Яр Чаллы) – ноутбук, 3 җөздә җиңү яулаган Аиша Кушматова (Әлмәт ислам мәдрәсәсе) 30 мең күләмендә акчалата бүләккә ия булды.

## Ютазы мөхтәсибәтендә мәетханә һәм төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Шәүвәл аеның 24 нче көнендә (14 нче майда) Ютазы мөхтәсибәтендә мөселман инфраструктурасы үсешенә караган берьюлы 2 бина ачылды:

Урыссу Үзәк мәчете янында мәетханә һәм Димтамак авылында капиталь ремонттан соң мәчет.

Мәетханәдә мәрхүмнәрне соңгы юлга озату, мәет юу, кәфенләү, җирләү кирәк-яраклары алу өчен барлык шартлар тудырылган.

Димтамак авылында капиталь ремонттан соң мәчет шулай ук, заман таләпләрен искә алып, барлык уңайлыклар булдырылып эшләнгән: бирегә мосафирлар тәүлек дәвамында кереп намаз укып чыга ала. 70 кеше сыйдырышлы мәчет 2004 елда кирпечтән төзелгән. Бер катлы гыйбадәт йортында тәһарәт алу һәм дини йолаларны башкару өчен барлык мөмкинлекләр бар. Төзекләндерү барышында мәчетнең җылыту системасы яңартылган, яңа идәннәр җылытып җәелгән, яңа калай түбә ябылган, бина һәм манара заманча төзелеш материаллары белән тышланган, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килгән электрүткәргечләр сузылган, мәчет янәшәсенә агач-куаклар утыртылган. Димтамак авылы мәчетенә имам итеп Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсен тәмамлаган Мөхәммәт хәзрәт Мәрданшин билгеләнде.

## Мөфти Казандагы күргәзмәне үзенең шәхси коллекциясеннән Коръән басмалары белән баетты

Шәүвәл аеның 26 нчы көнендә (16 нчы майда) «Казан Кремле» музей-тыюлыгының Ислам мәдәнияте музеенда тантаналы рәвештә «Казан Коръәне» күргәзмәсе ачылды. Ул Казан басмасының – Әр-Рәсм әл-Госмани таләпләренә туры килгән Кәлам Шәриф – басылып чыгуның 220 еллыгына багышлап оештырылды.

Күргәзмәдә Казан университеты, Казан Кремле музей-тыюлыгы һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның шәхси коллекциясеннән барлыгы 85 Коръән китабы тәкъдим ителде. Мөфти хәзрәт 15 китап тапшырды. Болар – XVIII, XIX гасыр кульязма Коръәннәре, төрле елларда дөнья

күргән басмалар. Кульязма Коръәннәрне күргәзмәдә күрсәтү шулай ук мөһим, чөнки басма Коръәннәрнең тарихы 220 ел вакытны үз эченә алса, кульязма Коръәннәрнең тарихы берничә гасырга ия.

## Казанда Russia Halal Market ярминкәсе узды

Казанның Агросәнәгать паркында «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» халыкара икътисадый форумы кысаларында Russia Halal Market хәләл продукция ярминкәсе узды. Хәләл маркетта сатыла торган барлык товарлар төрле оешмаларда сертификацияләнгән иде һәм Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча Комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә тикшерелде. Аерым алганда, Комитет белгечләре ярминкәдә эшләүче сатучыларның һәм җитештерүчеләрнең чималын, продукциясен, шулай ук сату-алу шартларының «хәләл» стандартларына туры килү-килмәвен карады. Комитет сату нокталарында «хәләл» нормативларын кертү буенча да эшләр башкарды: дуңгыз ите сатудан алынды, ритуаль чисталыкка ирешү өчен, бина һәм җиһазлар җентекләп чистартылды, ремонт ясалды, бәдрәф бүлмәләре тәһарәт алырлык итеп җиһазландырылды, хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен аерым намаз уку урыннары булдырылды.

Russia Halal Market-та 400 ләп сату ноктасында дөньяның 50дән артык иленнән, шул исәптән Россия, Казахстан, Беларусь, Мисыр, Иран, Малайзиядән кайтартылган продукция тәкъдим ителде. Россия экспонентлары арасында Татарстанның 20 районы, шул исәптән Казан шәһәре, шулай ук Саха Республикасы вәкилләре дә бар иде. Кунакларга тәм-том, ит һәм сөт, умартачылыктан алынган ризыклар, эчемлекләр, БАДлар, төрле соуслар, кием-салым һәм косметика, шулай ук халык иҗаты эшләнмәләре тәкъдим ителде.

## Татарстан мөфтие «RUSSIA HALAL EXPO» Халыкара хәләл индустриясе күргәзмәсен Коръән укып ачты

Шәүвәл аеның 28-29 нчы көннәрендә (18-19 нчы майда) «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә «Россия – Ислам дөньясы: Kazanforum 2023» Халыкара икътисади форумы узды. 18 нче майда әлеге форум кысаларында «RUSSIA HALAL EXPO-2023» Халыкара хәләл индустриясе күргәзмәсе ачылды. Беренче булып тантанада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады – ул экспозицияне Коръән укып ачып җибәрде.

Russia Halal Expo – Россиядә инвестиция һәм инфраструктура проектларының иң зур күргәзмәсе. Ул бизнес-проектларны үстерү өчен уникаль урын, форумда катнашучылар арасында конструктив диалог төзү өчен мәйданчык булып тора.

Биредә иң кызыклы экспозицияләрнең берсе ТР мөселманнары Диния нәзарәте мәйданчыгы булды. Быел ТР мөселманнары Диния нәзарәте экспозициясендә мөфтиятнең халыкара эшчәнлеге буенча тәҗрибәсе тәкъдим ителде. Кунаклар игътибарына берничә телдә шәригать стандартлары буенча әзер банк продуктлары, шулай ук икътисадның төрле тармакларындагы хәләл продуктлар, ислам финанслары һәм хәләлне сертификацияләү буенча белгечләр әзерләү программалары, мөселман медиапроектлары, хаҗ программалары һ. б. тәкъдим ителде. Шулай итеп, экспозициядә ислам ипотекасы, «Хозур ТВ» мөселман телеканалы, онлайн-мәдрәсә, тематик мобиль кушымталар һ. б. белән танышырга мөмкин булды.

## KazanForum-2023 интерактив зонасында мөселман эрудитлары «MuslimQuiz» акыл көрәшендә ярышты

«Россия – ислам дөньясы: KazanForum» XIV Халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында мөселман эрудитлары өчен ислам турында «MuslimQuiz» интеллектуаль уены узды. Яшьләр катнашындагы 2 интеллектуаль ярышны рус һәм инглиз телләрендә Татарстан Диния нәзарәте оештырды. Мөселман эрудитлары уеннарында дөньяның төрле илләреннән 140 кеше катнашты: Россия, Төрекмәнстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Бангладеш Халык Республикасы. Россия командасы составында – КИУ студентлары һәм белгечләре, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Чистай мөхтәсибәте мөселманнары, «Госмания» мәктәбе, махсуслаштырылган укыту фәнни үзәге – «IT-лицей» мәктәбе, «Сетевая компания» АҖ, КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге вәкилләре һәм башкалар.

## Дагыстаннан Татарстанга беренче тапкыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренең чын ядкәрләре килде

Шәүвәл аеның 29 нчы көнендә (19 нчы май) – изге җомга көнендә – Г. Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренең чын ядкәрләрен тантаналы рәвештә каршы алдылар. Кыйммәтле йөкне Дагыстан мөфтие урынбасары Мөхәммәдрасүл хаҗи Саадуев җитәкчелегендәге Дагыстан Республикасы делегациясе озата килде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренең 10 ядкәре арасында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең май кәсәсе һәм кылычы, сәхабә Билял радыяллаһу ганһе, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә һәм кызы Фатыйма

радыяллаһу ганһә чүлмәкләре, аның кул тегермәне, Халид бине Әл-Вәлид радыяллаһу ганһенең сәфәрләрдә йөртә торган фляжкасы һәм көбәсе, Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк радыяллаһу ганһенең пычагы бар иде. Бу экспонатларны Татарстанга беренче тапкыр алып килделәр. Алар Дагыстанда мөфти Әхмәд хаҗи Абдуллаевка тапшырылган әманәт булып саклана.

Зөлкагъдә аеның 1 нче көнендә (21 нче майда) әлеге уникаль экспозиция шәһре Болгарда Истәлек билгесе бинасында Изге Болгар җыенында катнашучыларга һәм кунакларга тәкъдим ителде. Күргәзмә ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә оештырылды. Күргәзмә Татарстан һәм Идел буе төбәкләре мөселманнары арасында зур кызыксыну уятты. Рәсми ачылышка кадәр үк ишек янында күргәзмәгә керергә теләүчеләрнең зур чираты җыелды. Күргәзмәгә керүчеләр экспозицияне берничә тапкыр карап узды, ядкәрләрне Татарстанга алып килүче Дагыстан кардәшләребез Коръәннән аятьләр һәм Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар укыды. Болгар музей-тыюлыгының якынча исәпләре буенча, Болгар шәһәрендә күргәзмәне ике көндә 30 меңнән артык кеше карарга өлгерде.

Күргәзмә Изге Болгар җыеныннан соң Казанга китерелеп, 22-23 нче май көннәрендә «Кол Шәриф» мәчетендә эшләде һәм зөлкагъдә аеның 4 нче көнендә (24 нче майда) тантаналы рәвештә Дагыстанга озатылды. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстанда күргәзмә оештыру өчен Дагыстан мөфтие Әхмәт әфәнде җибәргән команда әгъзаларына рәхмәт белдерде. Аерым алганда, Камил хәзрәт экспозициянең татарстанлыларда Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәхесенә һәм аның Сөннәтенә карата зур кызыксыну уятуын, Аллаһы Тәгаләнең Татарстанга бәрәкәт бирүе өчен сәбәп булуын, җәмгыятьтә Ислам кыйммәтләрен ныгытуын билгеләп үтте.

## Kazanforum-да Нәзарәтнең «Хәләл» комитеты «Магнит» ваклап сату челтәре белән меморандум имзалады

Шәүвәл аеның 29 нчы көнендә (19 нчы майда) «Россия – ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты буенча Комитеты «Тандер» акционерлык җәмгыяте («Магнит» ваклап сату челтәре) белән меморандум имзалады. Килешүне имзалауда «Хәләл» стандарты буенча Комитет җитәкчесе Габбас хәзрәт Шляпошников һәм «Тандер» компаниясе генераль директоры урынбасары, ваклап сату челтәре директоры Руслан Исмәгыйлов катнашты. Сөйләшүдә катнашучылар хәләл ризык җитештерүчеләр белән хезмәттәшлек итү мөмкинлекләре турында фикер алышты, шулай ук «Магнит» ваклап сату челтәре белән «Хәләл» стандарты буенча Комитет арасында хезмәттәшлеккә әзер булуларын белдерде.

## Казанда тантаналы рәвештә «Казан басмасы» бастырылган бинада истәлек тактасы ачылды

Шәүвәл аеның 30 нчы көнендә (20 нче майда) КФУның төп бинасы ишегалдында тантаналы рәвештә мөселман дөньясында беренче басма Коръән – «Казан басмасы» бастырылу вакыйгасын мәңгеләштергән истәлек тактасы ачылды. Элмә тактада татар, рус һәм гарәп телләрендә: «Бирედә 1803 елда мөселманнар тарафыннан Г. Бурашевның «Азия басмаханәсе»ндә соңрак «Казан басмасы» буларак танылган Кәлам Шәриф бастырылды. Шул вакыттан Казан дөньяда Коръән дөньяда күпләп бастырылган беренче шәһәргә әверелде», – дип язылган.

Тантананы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ачып җибәреп, «Әл-Хәшер» («Җыен») сүрәсеннән 21–24 аятьләр укыды. Шунысы игътибарга лаек, Коръәнне бастыру традицияләре Казанда бүген дә дәвам итә: 2017 елда

Россиядә беренче тапкыр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте әзерләгән Коръән басмасы халыкара стандартларга туры килә дип танылды, шуннан соң ул Үзбәкстан, Төркия һәм Белорусиядә дә дөньяга чыкты, ә 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100-еллыгы кысаларында Нәзарәт «Казан басмасы» дип исемләнгән компьютер шрифтын эшләде һәм аның нигезендә яңартылган «Казан басмасы»н әзерләп бастырды.

## Казанда «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы пленар утырышы үтте

Шәүвәл аеның 30 нчы көнендә (20 нче майда) Казанда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы пленар утырышы үтте. Форумга Россия Федерациясенең 77 төбәгеннән 1000 дин әһеле һәм кунак килде. Һәр елдагыча форум делегатлары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен җыелды.

Форумның пленар утырышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Ул үз чыгышында 2022 елда «Сахих Әл-Бохари»ның бер тәрҗемәсе тыелуны искәртеп, бу вакыйгадан Россия мөселманнарына үзләре өчен дөрес нәтиҗәләр чыгарырга кирәклеген ассызыклады. Ул мәсьәләнең чишелешен дә тәкъдим итте: шуның беренчесе – татар дин әһелләренә дини хезмәтләрне татар телендә язу һәм бастыру белән бәйле. Икенче тәкъдим дини әдәбиятны тикшерү өчен, Россиякүләм дини экспертлар оешмасы төзүгә кагылышлы. Мөфти хәзрәт шулай ук татар дин әһелләренә Татарстан мөфтияте һәм «Хозур» нәшрияты ярдәмен дә тәкъдим итте: «Татарстан Диния нәзарәтенең уңай тәҗрибәсе бар – бездә экспертлар шурасы эшли, ул китапларны дөньяга чыгарганчы тикшерә, шул рәвешле басмаларны тыюдан үзенә күрә бер саклык чарасы күрелә», – диде Камил хәзрәт һәм Диния нәзарәтенең фундаменталь басмаларны башка мөфтиятләр белән

хезмәттәшлектә чыгару тәҗрибәсе белән дә уртаклашты. Билгеле булганча, Сахих Әл-Бохариның «Зөбдәт» исемле кыскартылган варианты һәм «Калям Шариф. Перевод смыслов» хезмәтен Татарстан мөфтияте Дагыстан мөфтияте белән берлектә әзерләп бастырды.

## Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча Комитетында хәләл туклануның онлайн-картасын эшләделәр

Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты буенча комитетында «ProHalal» мобиль кушымтасы эшләнде. Бу – хәләл җәмәгать туклануы урыннары, хәләл һәм харам кушылмалары һәм азык-төлек өстәмәләренең мәгълүмати белешмәлеге. Гади генә әйткәндә, белешмәлек мөселманнарга Татарстандагы күпсанлы хәләл кафе һәм рестораннарны табарга, теге яки бу ашамлыкны, составына карап, куллану-кулланмау турында мөстәкыйль рәвештә карар кабул итәргә ярдәм итәчәк. Мобиль кушымта әлегә сынау рәвешендә эшли.

## Татарстан мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе башланды

Татарстан мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе башланды. Мөселман дини белемен алырга теләүчеләргә сайлап алу мөмкинлеге зур: Татарстанда 8 мәдрәсә, Россия ислам институты, Казан ислам университеты, Болгар ислам академиясе бар. Әлеге уку йортларының кабул итү комиссияләре дүшәмбедән җомгага кадәр эш сәгатьләрендә телефон аша татар һәм рус телләрендә консультацияләр бирергә әзер. Документлар июль ахырына кадәр кабул ителә. Август башында кабул итү имтиханнары башлана. Мөселман уку йортларында белем бирү көндезге, читтән торып һәм көндезге-читтән торып уку бүлекләрендә алып барыла. Гомумән алганда,

быел республика мөселман уку йортлары көндезге бүлеккә 400дән артык шәкерт кабул итәргә әзер, ә калган уку бүлекләрендә 750 кеше өчен урын каралган.

## Җәйге каникул чорында Татарстан мәчетләрендә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары уза

Җәйге каникул чорында Татарстан мәчетләрендә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары уза. Күркәм гадәт буенча сабыйлар өчен белем бирү, танып белү һәм күңел ачу чаралары кысаларында кызыклы программалар әзерләнде. Ул әхлак һәм тәрбия, Ислам нигезләре, Коръән дәресләрен, шулай ук күңелле чаралар: шаян уеннар, бәйгеләр, сабантуйларны һ.б. үз эченә ала.

## Казанда иң көчле яшь мөселман фәнсөярләре ачыкланды

Зөлкагъдә аеның 10 нчы көнендә (30 нчы майда) Казанда «Туган авылым» милли-туристик комплексында мөселман яшьләре өчен «MuslimQuiz»ның алтынчы – финал уены үткәрелде. 2022-2023 ел сезонында барлыгы 5 очрашу узды. Финал уеннар тарихында күбрәк кеше катнашу һәм командалар җыелу белән тарихка кереп калды. Болар – ике сезон дәвамында көч сынашкан командалар, арада KazanForum-да катнашып, уенны ошатып өлгергән яшьләр дә бар иде. Шулай итеп, финалда алтышар кешедән торган 31 команда (180 уенчы) катнашты. 2022-2023 ел сезонында җиңүче дип «Команда  №1» яшьләре табылды.

Моннан тыш, 2023 елның 18-19 нчы май көннәрендә «Россия – ислам дөньясы: KazanForum» XIV Халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында да ике уен оештырылды.

## Республика балалар клиник хастаханәсе янында рухи үзәк төзелә башлады

Зөлкагъдә аеның 12 нче көнендә (1 нче июньдә) Халыкара балаларны яклау көне кысаларында Республика балалар клиник хастаханәсе җирлегендә тантаналы рәвештә «Тыныч бакча» рухи үзәк комплексы төзелеше башланды. Комплекс «Әбүгалисина» мәчетеннән һәм православ чиркәүдән тора. Аларның проектлары белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановны таныштырдылар. Йөз квадрат метрлы мәчет аның теләктәшлегендә, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Ханский дом» төзелеш компаниясенең актив катнашында РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе ярдәме белән торгызыла. Төзелеш 2024 елда тәмамларга ниятләнә. Мәчет бер катлы, балконлы, 60–70 кеше сыйдырышлы. Шул ук бинада барлык уңайлыклары булган тәһарәтханә дә урын алачак.

Тантанада булачак мәчет нигезенә киләчәк буыннарга хат һәм сабыйлар ясаган рәсемнәр белән истәлекле капсула салынды. Әлеге символик гамәлне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм мөселман эшмәкәре Айдар Шаһимәрданов башкарды.

## Казанда 17 корбан чалу урыны билгеләнде

Казанда быел Корбан гаетенә әзерлек барышында рәсми рәвештә корбан чалу өчен 17 мәйданчык расланды. Биредә корбан чалу бәйрәм намазыннан соң башланып китеп, өч көн дәвам итте. Казыйлар һәм Голәмәләр шуралары тарафыннан билгеләнгән нисаб 36 000 сумны тәшкил итте.

## 2023 елда Татарстаннан 1800 кеше хаҗ кылды

Быел «ДУМ РТ Хаҗ» Татарстанның рәсми хаҗ операторы аша республикадан 1800 кеше хаҗ кылды. Алар өчен «Эконом комби», «Эконом авиа», «Стандарт» һәм «ВИП» программалары эшләнде. Хаҗиларның беренче

төркеме изге җирләргә 8 июньдә кузгалды. Соңгы төркем юлга 22 июньдә чыкты. Хаҗилар Татарстанга 5 июльдә кайта башлады.

Хаҗиларны төрле белгечлектәге 20 табиб – кардиолог, травмотолог, гинеколог, инфекционист һ.б. озата барды. Барлык хаҗилар да ковид, менингит һәм дифтериядән прививка ясатты.

## Габдрәхим Утыз Имәни мәчетендә Корбан бәйрәме узды

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә (28 нче июньдә) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм – Корбан гаетен билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Башкалада төп бәйрәм тантанасы яңа ачылган Габдрәхим Утыз Имәни мәчетендә узды. Гаеткә килгән мөселманнар, бәйрәм вәгазен тыңлап, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә намаз укыды. Галиев мәчетендәге бәйрәм чараларын «ТНВ Татарстан», «ТНВ Планета» телеканалы аша турыдан-туры карарга мөмкин булды. Туры эфир шулай ук Нәзарәтнең dumrt.ru сайтында һәм «Хозур ТВ»ның YouTube каналында да оештырылды.

# Нәсыйхәт

# Татар мәкаме белән азан әйтү турында

Татар теленә «азан» сүзе ничек һәм каян килеп кергәнлеге турында уйлап караганыбыз бармы? «Азан» сүзе Коръәндә нибары бер тапкыр гына телгә алына, һәм җир йөзендә беренче азан әйтүче буларак, анда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәтле 3000 ел элек яшәгән бабасы Ибраһим галәйһиссәлам хакында сүз бара:

وَإِذْ بَوَّأْنَا لِإِبْرَٰهِيمَ مَكَانَ ٱلْبَيْتِ ﴿٢٦﴾ وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَىٰ كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِن كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ

**«Ибраһимга [галәйһиссәлам] йортның урынын күрсәттек. Кешеләр арасында хаҗны [фарыз буларак] игълан ит, җәяү һәм һәр ерак юлдан килгән арык [һәм алҗыган] дөя өстендә сиңа килсеннәр».**

«Әл-Хаҗ», 22:26-27

Шулай итеп, җир йөзендәге беренче мөәзин Ибраһим галәйһиссәлам булганлыгы аңлашыла. Тормышының азагында борынгы бабалары корган йортның нигезен – кыйбласын табып, асылына кайткан Ибраһим галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгалә азан әйтеп, җир йөзендә таралып яшәгән адәм балаларын шушы җирләргә хаҗга чакыруын әмер итә.

Ибне Кәсир тәфсирендә хәбәр ителгәнчә, мондый боерыкны ишеткәч, Ибраһим галәйһиссәлам аптырап кала: «Шушы чүл уртасында әйткән азанымны кем, ничек ишетсен, йә Раббым?!» – ди. Моңа җавап итеп Раббыбыз: «Син азаныңны әйт, кешеләрне чакыр, чакыруыңны аларга Мин Үзем җиткерермен!» – ди. Димәк, азан – ул иң элек җан авазы! Күңел түрләреннән чыккан шөкрана белән сагыш хисләренең тышка ташып, авазга әверелгән, – сүз калыбына салынган күңел тибрәнүләре ул азан! Һәм Ибраһим галәйһиссәламнең күңеле мондый хис һәм хатирәләр белән, чыннан да, тулы иде.

Озак еллар Раббысын эзләгәннән соң, ул эзләгәнен таба. Раббыбыз аңа гасырлар буена ком астында күмелеп яткан һәм кайчандыр җәннәттән сөрелеп, җирдә яңадан кавышкан Адәм белән Хәвваның корган йортларының нигезен күрсәтә. Бу юлы ул Раббыбызга тугрылыгын раслар һәм Аңа тагы да якынаер өчен, хатыны Һаҗәр белән бәләкәй улы Исмәгыйльне, шушы комлы чүл уртасында калдырып китә, чөнки күңел күзе белән ул бу җирләрнең кайчандыр яшеллеккә күмелеп ятканын, – җәннәтне хәтерләткәнен күреп тора, димәк, – Раббыбыз аны бу очракта да ярдәмсез ташламаячагына ул катгый ышана иде. Һәм Раббысына ул болай дип дога кыла:

رَّبَّنَا إِنِّي أَسْكَنتُ مِن ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِندَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلَاةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِّنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُم مِّنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ

**«Ий Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, харам кылынган йортың янында урнаштырдым. Ий, Раббыбыз! Намаз укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен авыштыр һәм аларны җимешләрдән ризыкландыр, – бәлки, алар шөкер итәрләр».**

«Ибраһим», 14:37

Һәм бөек Аллаһы Ибраһим галәйһиссәламнең мондый фидакарьлеген һәм тәвәккәллеген тиешенчә бәяли. Ибраһим хөрмәтенә комлы чүл уртасында 3000 ел бертуктаусыз агып ята торган чишмә; ә чүл астында, – Исмәгыйль нәселен 3000 елдан соң да дөньяның иң мул яшәүче кешеләреннән итәчәк кара алтын диңгезен булдыра! Ләкин Ибраһим галәйһиссәлам, чын пәйгамбәр һәм Аллаһының хакыйкый колы буларак, үзеннән соң нәсел дәвамчысы гына түгел, – ә болардан да күбрәк, – үзе башлап киткән эшенең дәвамчысы булуын тели. Һәм шуңа күрә ул Аллаһыга болай дип ялвара:

رَبَّنَا وَابْعَثْ فِيهِمْ رَسُولًا مِّنْهُمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِكَ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَيُزَكِّيهِمْ ۚ

**«Ий Раббыбыз! Алар арасыннан Синең аятьләреңне укыячак, Китапны һәм Хикмәтне өйрәтәчәк һәм аларны сафландырачак бер пәйгамбәр җибәр!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:129

Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәламнең бу догасын да тормышка ашыра. Улы Исмәгыйль нәселеннән пәйгамбәрләрнең иң ахыргысын – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәрә. Моның хакта Пәйгамбәребезнең дә: «Мин – Ибраһимның [тормышка ашкан] догасы...» – дип әйткәнлеге мәгълүм (Әхмәд бине Хәнбәл, № 5/262).

Әмма Ибраһим галәйһиссәламнең бу догасы тормышка ашканчы әле күп гасырлар уза. Кайчандыр бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылу өчен билгеләнгән Кәгъбә тирәсендә дә ялган илаһлар – потлар күренә башлый. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында инде Ибраһим улы Исмәгыйль нәселеннән булган гарәпләр, дөньяга бирелеп, Кәгъбәне бөтенләй уен-көлке урынына әйләндереп бетергәннәр иде.

Шулай булгач бүген без, бабаларыбыз дин өчен чиккән җәфаларның мәгънәсен аңламыйча һәм алар диннәрен саклап калу өчен биргән корбаннарның бәясен белмичә, татар мәкаме белән азан әйтү бәйгеләре уздырырга хакыбыз бармы дигән сорау туа. Хакыбыз булса да, татар азанының, татар азанчыларының тарихларын белмичә, аларча әйткән азаннарыбыз моңсыз бер тәклидкә генә охшап калмасмы? Чөнки безнең бабаларыбыз да, Ибраһим галәйһиссәлам кебек, диннәреннән ваз кичмәс өчен, туган җирләреннән сөрелгән, утка-суга ташланган, чит җирләргә качып китәргә мәҗбүр булган. Һәм шуңа күрә милләтебезнең һәм бигрәк тә аерым шәхесләребезнең аянычлы, корбаннар һәм югалтулар тулы тарихын

белмичә, – аны йөрәгебез аша уздырмыйча, татар макәмен торгызу һәм булдыру эше тәклидкә генә кайтып калачак. Мондый моңсыз азаннарга колак салучылар булса да, мәчеткә килеп намаз укырга теләүчеләр саны артмас! Сабый балаларыбызга исем кушканда да колакларына әйтелгән мондый моңсыз азаннар, аларның хәтер күзәнәкләрен кузгата алмас! Чөнки азан – ул гасырлар авазы булып яңгыраган дәгъват алымы, иманга чакыру ул!

Нәсыйхәтебезне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 100 ел элек язып калдырган шигырь юллары белән тәмамлау урынлы булыр, бүгенге көн азанчылары өчен дә бу юлларда күркәм бер вәгазь бардыр:

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен!*

*Альберт Кадыйров,*
*Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе*
*мәчете мәхаллә әгъзасы,*
*тәрҗемәче*

# Иман һәм сугыш (Җиңүнең 78 еллыгына багышлана)

Кеше өчен иң кадерле төшенчә – ул гомер. Ул Аллаһы Тәгаләдән бер генә тапкыр бирелә. Бу хакыйкатьне белә торып, Николай Островскийны кабатлап шуны әйтәм: ул гомерне «максатсыз үткән еллар өчен газапланмаслык итеп» үткәрергә кирәк.

Яшьлек елларында да һәм үзенең туксанга җитеп килгән, аннан да арткан яшендә дә һәрберебез: «минем бөтен тормышым аңлы рәвештә дөньядагы иң күркәм эшкә – бүгенге көндә авырлык кичерүче кешеләргә ярдәм итү өчен көрәшкә багышланды», дип әйтерлек булсын.

Бәлага дучар булган бер кешегә, кешеләр төркеменә, җәмәгатьчелеккә, илгә, дәүләткә ярдәм итү – ул умырткалык, барлык алга киткән диннәрнең: мөселман, насара, православия, католик, яһүди, протестант һәм Көнчыгыш халыклары диннәренең иң мөһим мәсьәләсе, төп нигезе.

Һәр кешегә, гаиләгә авыр булган. 1941 елның 22 нче июнендә фашистлар Аурупа Үзәк һәм Көнбатыш илләрен алып, буйсындырылган илләрнең матди һәм рухи байлыкларын үзенеке итеп, илебезгә килеп кергәндә ни дәрәҗәдә кыен булган!

Библиянең беренче чыганакларында һәм Коръәни Кәримнең аятьләрендә аңлатылган илаһи күрсәтмәләрне истә тотып, рус, татар, белорус, украин милләте халыклары, Кавказ, Урта Азия, Себер, Ерак Көнчыгыш республикалары халыклары зур дошман – фашизм белән көрәштә берләште.

Шайтан белән көрәштә безне гомумкыйммәтләр берләштерә иде.

Берләштерү башлангычының нигезенә Аллаһы Тәгалә мөһим төшенчә – «толерантлык» – ватандашларыбызның үзенчәлекләренә, аларның дөньяга карашларына, фикер йөртүләренә, дөньяны күзаллауларына һәм, әлбәттә инде, дин тотуларына карата хөрмәт салган иде. Дуслык – бердәмлек, уңыш, җиңү ачкычы.

Моннан чыгып, фашистлар 1939 елда башлап җибәргән сугышны, сигез ел элек Украина шайтаннары тарафыннан башланган сугышны кяфер Иблис гамәле дип әйтеп була.

Диннәр арасында Аллаһы Бер, фәрештәләр һәм пәйгамбәрләр бер, Изге Китаплар төрле чорлар һәм барлык халыклар өчен Бер.

– татар кешесе Габдрахман өчен аерым илаһ юк;

– рус кешесе Иван өчен аерым илаһ юк;

– яһүд кешесе Аврам өчен аерым Яхфә юк.

Без дини йолаларны үтәүдә аерылабыз. Әмма бусагада фашист-кяфер торганда иман китерүчеләргә аермалык эзләү – гөнаһ. Шулай булгач, фашист-кяферне җиңү өчен, төрле дин тотучыларны берләштерә торган илаһи гыйлемнәрнең нигезен, кешелек яшәеше нокталарын бертуктаусыз эзләргә кирәк.

Менә ни өчен сугыш башында Советлар Союзындагы барлык дини оешмалар совет дәүләтенә лояль мөнәсәбәттә булу позициясенә күчкән, бу сугышның беренче көннәреннән үк патриотик караш формалашуга сәбәп булган. 1941 елда, рус-православия чиркәве башлыгы митрополит Сергий һәм, шулай ук, Советлар Союзы мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте, патриотик рухтагы хат белән, Аллаһыга ышанучыларга мөрәҗәгать итте.

СССРның дини оешмалары арасыннан беренче булып Үзәкләшкән дини оешма – мөселманнар Диния нәзарәте, мөфти Габдрахман Расүлев җитәкчелегендә алман фашистларының яулап алулары хакында иман китерүчеләргә патриотик рухтагы мөрәҗәгатьне бастырып чыгарды.

Дингә ышанучылар исеменнән мөфти болай диде: «Фашистлар Германиясенә һәм аның ялчыларына каршы барган бу Бөек Ватан сугышында үзегезнең хаклы булуыгызны исбатлап, бөтен дөнья каршында үз Ватаныгызга тугры булуыгызны күрсәтегез, Кызыл Армиянең җиңүе өчен мәчетләрдә дога кылыгыз. Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы Тәгаләгә дошманны тизрәк җиңү, барлык кешелекнең, мөселман дөньясының залимнәрдән – фашистлардан котылу хакында дога кылып сорагыз».

Мин үзебезнең Балтач районы Чутай авылы имамы Нурзадә хәзрәт Нәсыйхне – дөньяга карашы буенча мөселман җәдиден яхшы хәтерлим. Ул Изге Китаптан һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең хәдисләреннән чыгып, фронтка китүче авылдашларны кяфер-фашистлар белән көчләрен һәм гомерләрен кызганмыйча яу кырында сугышырга чакырган иде. Ул: «Яу кырына баручы сугышчыга ярдәм итү сугышта залим белән көрәшүгә тиң»,– дип әйтә иде.

Дини оешмалар илнең оборонасы фондына акчалар җыюны оештырып, үз өлешләрен кертте.

ТР Рәисе Р.Н. Миңнеханов: «Бердәм халык, бердәм ил булып без сугыш авырлыкларын һәм сынауларын уздык. Сугыш чоры буыны вәкилләренең барлык гамәлләре һәм фикерләре бер генә максатка корылган иде – түзем булу, исән калу һәм җиңү. Бөек Җиңүнең сугышчылары үзләренең тарихи йөкләмәләрен тиешле дәрәҗәдә башкарды, илгә һәм бөтен дөньяга нацизм коллыгыннан азатлык алып килде», – дип әйтә.

«Язмыш безнең Ватанны гаять җаваплы тарихи хәлләргә куйды. Россия шул ук вакытта насара һәм Ислам дине иле. Бу аңа махсус вазифалар йөкли. Бер яктан, Россия күпконфессияле держава һәм үз халкы арасындагы күршеләрчә мөнәсәбәтләрне сакларга, икенче яктан, ул бу күркәм мөнәсәбәтләрне дөньяга тапшырырга тиеш. Татарстан моңа әзер, яңа чорда хасил булган тәҗрибә дин ирегe белән тулы».

Шул ук вакытта Россиянең православия вәкилләре һәм мөселманнар шуны онытмаска тиеш: бүген, россиялеләрнең әкрен, әмма мәҗбүри рәвештә матди халәтләренең яхшыруы шартларында кешеләрнең рухи дөньясы, әйтерсең лә, кирегә бара торган арифметик прогрессия сыман, түбән төшә. Шуңа да әхлакны тәрбияләү проблемалары башка вакытка караганда да, иң актуаль, җаваплы бурыч булып тора. Һәм бу бурыч аерым һәрбер кеше өстенә, шулай ук, мәктәп, җәмгыять өстенә тапшырыла

Мисал китерик, әйтик, бүген «а» классында расписание буенча физика фәне бара. Тема – «электр тогы». Физика укытучысы балаларга электр тогының ябык үткәргечтә ирекле электроннарның тәртипле хәрәкәте булуын, бу хәрәкәтнең электр йөртү көче тәэсирендә башкарылуын аңлата. Димәк, электр тогының хәрәкәте тәртипкә салынган гамәл.

Ә «б» классында астрономия фәне укытучысы «галактика» темасы буенча дәрес бирә, Галәмдә миллиардтан артык галактика барлыгын, аларның һәрберсендә миллиардка якын йолдызлар, планеталар булуын аңлата. Аларның барысы да килешенгәнчә, үзләренең күчәрләре, траекторияләре, орбиталары әйләнәсендә хәрәкәт итә. Моның белән бергә аларның берсе дә икенчесенең юлын кисеп үтми. Димәк, Галәмдә галактикаларның, йолдызларның хәрәкәте тәртипкә салынган.

Ә нинди Көч аларны барлыкка китергән һәм ирекле электроннарның, галактикаларның, йолдызларның хәрәкәтләрен тәртипкә салган? Иван, синме? Юк! Габдрахман, синме? Юк! Император, синме? Юк! Синме, губернатор? Юк! Димәк, Халык кылучы бар. Галәмнәрнең Бөек Яратучысы бар! Аның исеме – Аллаһы Тәгалә! Ул Бердәнбер, Ул Галәмнәрнең Хуҗасы.

Җирдә һәм күкләрдә җайга салынганлык, барлык диннәр һәм фәннәр: математика, биология, химия, география, механика, проза, медицина, компьютер технологиясе һәм башкалар, Аллаһы Тәгалә тарафыннан тормышка ашырылган өзлексез яңартылуда тора.

Укытучының бурычы – бу тәртипкә салынган кануннарны диннәр һәм фәннәр бердәмлегендә табу, тану һәм дәрестә боларны укучыга аңлатып бирә алу.

Укытучының һәм укучының рухи дөньясы диндәге төзеклек һәм фәнни танып-белүнең төрле формаларын үзенә туплап, һәр дәрестә, темада толерантлык, дин ирекен тану таләпләрен саклап алып барыла.

Сүз дин дәресен укыту хакында түгел, ә Яратучыга ышанучы һәм үз фәнен яхшы белүче укытучының дәрес азагында әлеге предметка һәм темага

кагылышлы, беркем белән дә инкяр ителми торган Изге Китаплардагы дәлилләрне аңлату өчен, биш минут вакыт табуы хакында бара.

Православия, яһүди, мөселман диннәре нигезенең бөтендөнья фәннәре ачышлары белән уртаклыгын аңлаган һәм кабул иткән очракта гына кеше үз-үзен таныячак. Кеше үз-үзен танып, Яратучыны таный һәм аңлы рәвештә Яратучының әйткәннәрен үти башлый, күндәмлек, дин иреген тану, өмет һәм ярату юлына баса.

*Харис Салих улы Салихов,*
*«Хәтер» мәчете имам-хатыйбы*
*Бөек Ватан сугышы инвалид-ветераны,*
*Россия гуманитар фәннәр академиясенең*
*хөрмәтле әгъзасы һәм академик,*
*ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*